Г.Г. Баттал-Таймас

ИКЕ БЕРТУГАН МАКСУДИЛАР

ДВА БРАТА МАКСУДИ

"ФЭН"

ТАТАРСТАН ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
ГУМАНИТАР ФӘННӘР БҮЛЕГЕ

Г. Г. БАТТАЛ-ТАЙМАС

ИКЕ БЕРТУГАН МАКСУДИЛАР

ТОРМЫШЛАРЫ, ИҖАТЛАРЫ ВӘ ӘСӘРЛӘРЕ

Төрекчәдән татар һәм рус телләренә тәрҗемә, кереш сүз, библиография, шәрехләр *Ә. Г. Кәримуллинныкы*

«Фән» нәшрияты
Казан
1999

АКАДЕМИЯ НАУК ТАТАРСТАНА
ОТДЕЛЕНИЕ ГУМАНИТАРНЫХ НАУК

Г. Г. БАТТАЛ-ТАЙМАС

ДВА БРАТА МАКСУДИ

ЖИЗНЬ, ТВОРЧЕСТВО И ТРУДЫ

Перевод с турецкого на татарский и русский языки, предисловие, библиография и примечания *А. Г. Каримуллина*

Издательство «Фэн»
Казань
1999

УДК 371 (09)
ББК 74.03
С Б23

ТФА Редакция-нәшрият советы карары буенча басыла
Печатается по постановлению Редакционно-издательского совета АНТ

Редколлегия: *М. Х. Хәсәнов* (җитәкче), *М. З. Зәкиев* (җаваплы редактор), *Ә. Г. Кәримуллин*
Редколлегия: *М. Х. Хасанов* (руководитель), *М. З. Закиев* (ответственный редактор), *А. Г. Каримуллин*

Г. Г. Баттал-Таймас. Ике бертуган Максудилар.—Казан, «Фән» нәшрияты, 1999.—144 б.

Күренекле тарихчы, тел-әдәбият белгече, журналист, җәмәгать-сәясәт эшлеклесе Габдулла Баттал-Таймасның (1883—1969) бу хезмәте 1957 елда Истанбулда төрек телендә дөнья күрде. Әсәрнең беренче бүлеге Россиянең 2 нче һәм 3 нче Дәүләт Думасы депутаты, төрки-татар «Милли-мәдәни мөхтәрияте»нең Милли идарәсе рәисе (премьер-министры), Сорбонна, Истанбул университетлары профессоры, тарихчы галим, Төркия Президентының киңәшчесе, Төркия мәҗлесе депутаты Садри Максудиның (1878—1957) тормышын һәм эшчәнлеген яктыртуга багышланган. Максудиларның икенчесе—Әхмәтһади (1868—1941)—тел галиме, педагог, журналист, нәшир, дин һәм җәмәгать эшлеклесе. Аның тормышы һәм эшчәнлеге тулысынча Татарстан җирлегендә үткән. Бу әсәр аларның тормышы һәм эшчәнлеге турында беренче хезмәт. Аны төрек теленнән Әбрар Кәримуллин тәрҗемә иткән. Хезмәт аның комментарийлары һәм автор турындагы мәкаләсе белән басыла.

© «Фән» нәшрияты, 1999.

Г. Г. Баттал-Таймас. Два брата Максуди.—Казань, изд-во «Фән», 1999.—144 с.

Эта работа видного историка, специалиста по татарской филологии, журналиста, общественно-политического деятеля Габдуллы Баттала-Таймаса (1883—1969) была издана на турецком языке в 1957 году в Истамбуле. В первой ее части освещена жизнь и деятельность Садри Максуди (1878—1957)—депутата 2-й и 3-й Государственных Дум, Премьер-министра тюрко-татарской автономной национально-культурной республики (Мухтарият), профессора Сорбоннского и Анкарского университетов, ученого, советника Президента Турецкой республики, депутата Турецкого меджлиса. Вторая часть посвящена его брату Ахмедхади Максуди (1868—1941), видному языковеду, педагогу, издателю, журналисту, общественному и духовному деятелю. Это первая работа о жизни и деятельности этих деятелей. Она переведена Абраром Каримуллиным с турецкого на татарский и русский языки и издана с его комментариями, с его вводной статьей об авторе книги Г. Баттале-Таймасе.

© Издательство «Фән», 1999.

«ИКЕ БЕРТУГАН МАКСУДИЛАР» АВТОРЫ Г. Г. БАТТАЛ-ТАЙМАС ТУРЫНДА

Җитмеш елдан артык матбугатыбыз битләрендә урын бирелмәгән Садри Максуди исеме турында соңгы елларда берничә материал күренеп алды. Бу академик И. Таһиров, профессор Я. Абдуллин, яшь галимәбез Ф. Гаффарова мәкаләләре. Бу юлларның авторы да аның турында ике нәрсә язып чыккан иде. Берсе «Идел» журналында (1991, № 10—11): С. Максудиның әле билгеле булмаган диярлек, III Дәүләт Думасында «Россиядә татарлар арасында пантюркизм» дигән, патша жандармериясе, христиан миссионерлары уйлап чыгарган уйдырма турында сөйләнгән, аны фаш иткән доклад белән бергә басылды. Татар халкының милли, сәяси азатлыгы өчен көрәштә зур эш башкарган, аның беренче Премьер-министры булган, әдип вә галим, тел белгече һәм профессор, дипломат вә Дума депутаты, публицист һәм әдәбият эшлеклесе дә булган, төрки халыклар дөньясында гына түгел, Аурупа зыялылары, сәясәтчеләре, галимнәре арасында да танылган бу бөек шәхес турында хәзерге татар укучыларның белүе, танышлыгы әнә шул берничә мәкалә белән генә диярлек чикләнә иде. 1994 елның 26—27 октябрендә Казанда, Татарстан Фәннәр академиясе Садри Максудиның тууына 115 ел тулу уңае белән халыкара фәнни конференция оештыруы мәдәниятыбыз тарихында зур яңалык булды. Шушы уңай белән матбугат битләрендә Садри Максуди турында хезмәтләр ешрак күренә башлады. Аның «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән китабы төрекчәдән татар теленә тәрҗемә ителеп «Мирас» журналы битләрендә дөнья күрде. 1914 елда Казанда басылган, сәяси актуальлеген бүген дә югалтмаган «Англиягә сәяхәт» дигән китабы фәнни редакцияләнеп «Казан утлары»на тапшырылды, шәт ул әсәр тиздән аерым китап булып та дөнья күрер. Садри Максуди турын-

да аның замандашы, аның белән шактый аралашкан Г. Батталның «Ике бертуган Максудилар» (Истанбул, 1959) дигән китабы татар һәм рус телләренә тәрҗемә ителеп менә сезгә тәкъдим ителә. Боларны халкыбызның зур зыялысын халыкка кайтаруда, аның эшчәнлеген киңрәк белү һәм таныту өлкәсендә эшнең активлашуы дип санарга кирәктер. Болар артыннан Садри Максудиның башка хезмәтләре дә халыкка кайтарылыр дип ышанып калабыз. (СССР җимерелеп илдә үзгәрешләр башлану нәтиҗәсендә Садри Максуди исеменә дә юл ачылып, аның турында басылып чыккан һәм аның әсәрләреннән басылган материалларны бу басманың ахырында китерелгән библиографик белешмәдән белә аласыз).

Биредә без, беренче чиратта, «Ике бертуган Максудилар» дигән шушы тарихи хезмәтнең авторы турында киңрәк тукталып китүне кирәк дип саныйбыз. Бу хезмәтнең авторы— шулай ук татар матбугатында 70 елдан артык исеме тыелган мәшһүр галим, җәмәгать эшлеклесе, Садри Максудиның фикердәше, аркадашы. Ул—Габделбари Габдулла улы Баттал (8.XII.1883—26.IV.1969). Төркиядә Ататөрек заманында төрекләргә «фамилия» бирү шаукымы чорында ул үзенең чын фамилиясенә өстәмә итеп «Таймас» кушаматын ала. Ул вакытта, мәсәлән, Гаяз Исхакыйга «Иделле», Садри Максудига «Арсал», Зәки Вәлидигә «Тоган» шикелле өстәмә кушаматлар беркеп калган.

Төркиягә киткәнче Габделбари китаплары Г. Баттал исеме-фамилиясе астында басылып килә. Библиографияләрдә, каталогларда шушы исем-фамилия астында күрсәтелә. Фамилиясенә «Таймас» исеме өстәлгәч, хезмәтләре «Г. Баттал-Таймас» исеме астында басыла. Укырга тәкъдим ителә торган бу китабы да шундый өстәмәле исем белән басылганга күрә, без биредә аны «Г. Баттал-Таймас» дип күрсәтәбез, «Г. Баттал» дип тә искә алабыз.

Габделбари Самара губернасы Бузулук өязе Яңа Атау авылында крестьян гаиләсендә дөньяга килә,башлангыч белемен авыл мәктәбендә ала, укуын Троицкидагы Нәкышбәнди шәех Зәйнулла Рәсуловның «Рәсулия» исемле атаклы мәдрәсәсендә дәвам итә. Мәдрәсәне тәмамлагач, белемен арттыру өчен Мисырга китә, Каһирәдәге атаклы Әл-Әзһар университетын тәмамлый. 1908 елда туган иленә кайта, бераз вакыт Оренбургта «Вакыт» газетасында эшләп ала, шуннан башлап матбугатта даими катнаша башлый. 1910 елның язында Троицкига килә һәм үзе укыган «Рәсулия»дә

гарәп теле, татар тарихы һәм әдәбияты буенча сабаклар бирә.

Фәндә аның беренче адымы шәкерт елларында ук башлана. 1903 елда Троицкида ул шагыйрь Акмулла шигырьләрен туплап, әдип турында мәкалә язып, аны дөньяга чыгара. Гарәп дөньясы, ислам тарихы белән тирән кызыксынган, Мисырдан күп нәрсәләр белеп, төшенеп кайткан Г. Баттал яңа хезмәтләр әзерли. Алар арасында аерым китап булып басылганнары—«Ислам философлары» (Җамалетдин Әфгани һәм шәех Мөхәммәд Абдулла турында монография), Сүрия галиме Никола Хаддадның бер әсәренең татар теленә тәрҗемәсе (Г. Батталның кереш сүзе һәм комментарийлары белән), тагы ике китап—«Мәгыйшать вә юллары», «Сөймәк вә өйләнмәк».

Троицкида Г. Баттал татар мәктәпләренә, мәгърифәт эшенә күп ярдәмнәр күрсәткән шәһәр бае Габделвәли Яушев турында бер хезмәт яза, ул 1912 елда аерым китапчык булып Оренбургта басылып чыга.

Г. Баттал мәдрәсәдә гади укытучы гына булмый. Татар уку йортларында кулланыла торган дәреслекләр аны кызыксындыра. Әгәр гарәп телен укыту өчен дәреслекләр җитәрлек булса, тарих укыту өчен махсус кулланма-дәреслекләр ул вакытта булмаган диярлек. Ул татар тарихы буенча махсус укыту эшен оештырган беренче педагог була. Татар тарихын укытуны оештыру уңае белән ул фәнни эзләнүләр дә алып бара, төрле чыганакларны өйрәнә һәм милли педагогикабыз тарихында татар халкы тарихы буенча мәктәпләр өчен беренче махсус дәреслек яза. Ул—«Төрек-татар тарихы», 1912 елда Казанда, «Өмед» типографиясендә авторның үз хисабына аерым китап булып басылып чыга. Күрәсең, татар мәктәпләрендә махсус рәвештә, фән буларак, милли тарихыбыз шушы елларда укытыла башлаган. Бу дәреслекне укытучылар, укучылар яратып каршы алган булса кирәк. Дәреслекнең 1913, 1914, 1916 елларда кат-кат басылуы шуны сөйли. 1916 елда бу дәреслек хәтта ике басма булып чыккан. Бу басмалар барысы да авторның үз хисабына чыгарылган.

Г. Баттал, әйтеп үткәнчә, гарәп теле һәм тарихтан гына түгел, әдәбияттан да дәресләр бирде. Ул вакытка кадәр дөнья күргән дәреслекләр белән генә канәгатьләнми, татар әдәбияты буенча Галимҗан Ибраһимов белән махсус «Яңа әдәбият» исемендә дәреслек әзерли, аның беренче басмасы 1914 елда басыла, алга таба яңа басмалары да чыга. Күрәсең, Г. Баттал әдәбият теориясен дә, татар мәктәпләрендә беренче буларак,

аерым курс итеп укыта башлаган. Революциягә хәтле әдәбият белеме буенча татар телендә махсус дәреслекне дә ул язган. Бу—«Назарият әдәбия», ягъни «Әдәбият теориясе». Ул 1913 елда, бу юлы да, авторның үз хисабына басылган.

Укучыларга тәкъдим ителә торган «Ике бертуган Максудилар» китабында Г. Батталның «Йолдыз» газетасына кайчан күчеп килүе, анда кем булып, ниләр эшләве турында мәгълүматлар бар. Без биредә аның бу эшчәнлегенә тукталмыйбыз. 1913 елда Казанга килеп бу газетада дүрт ел эшләгәннән соң ул аннан китә. Октябрь революциясенә булган өметләре челпәрәмә килгән Г. Баттал милли-сәяси эшләргә кереп чума, татар социалист-революционерларына якынлаша. Татар эсерларының күренекле лидерларыннан булган Фуад Туктаров белән «Корылтай» газетасын оештыра. Аннан Җамалетдин Вәлиди, Мөхетдин Корбангалиев белән бергәләп, мәктәпләргә дәреслекләр басу өчен, шул газета исемендә нәшрият ачып китап бастыру эшенә керешә.

Г. Баттал—1917 елның ноябрендә Уфада ачылган Эчке Россия һәм Сибирия төрек-татарлары Милли мәҗлесендә депутат, Милли мәҗлес эшендә актив катнашучылардан берсе.

Казанда властька большевиклар килгәч, 1918 елның башында «Корылтай» газетасы Совет органнары тарафыннан ябыла, Казанны ак чехлар большевиклардан арындыргач, Г. Баттал Казанга кайта һәм «Корылтай» газетасын яңадан торгыза. Казанны кызыллар кире алгач, Совет органнары газетаны яңадан яба. Журналистика җене кагылган, сәяси эшкә кереп киткән Г. Баттал тагын бер газета оештыра. «Алтай» исеме белән бу газетаның бары 13 саны гына чыгып кала, ул да туктатыла. Г. Баттал кулга алына. Аны: «Моннан соң бернинди газета-фәлән чыгармаска вәгъдә бирәм»,—дигән шарт белән имза алып, төрмәдән чыгаралар.

Уфаны яңадан кызыллар алгач, Милли мәҗлес куыла, аның депутатларын кулга алу башлана. Мондый шартларда Милли мәҗлес депутатлары һәм аның Милли идарәсе әгъзаларының иректә калганнарының бер өлеше Себергә—Кызылъярга (Петропавелга) юнәлә һәм анда бу Милли мәҗлес «Күче Милли мәҗлес» исеме астында эшен дәвам итә. Себергә күчеп китүче депутатлар арасында Г. Баттал да була. Ул анда, Г. Исхакый һ. б. белән бергә, «Маяк» исемендә газета чыгаруда да катнаша. (Безгә бу газетаның басмаларын күрергә туры килмәде, аның «Күче Милли мәҗлес» органы булуы да мөмкин).

Себергә большевиклар үтеп кергәч, Милли мәҗлес депутатлары төрлесе төрле якка тарала. Бер өлеше Ерак Көнчыгышка, Кытайга барып чыга, кайберләре Идел, Урал буйларына юнәлә. Г. Баттал гаиләсе янына Казанга кайта, биредә татар мәктәпләре буенча бер җәмгыять оештырып, эш кузгатып йөри... 1920 елның гыйнварендә ЧК органнары аны кулга алып, хәзер Черек күл дип даны чыккан төрмә подвалына ябалар. Ул ниндидер юл белән төрмәдән кача. (Г. Батталның Төркиядә басылган истәлекләрендә ул турыда мәгълүматлар булырга тиеш.) «Кызылармеец» исеменә документ оештырып, ул Әстерханга юнәлә, аннан 1920 елның июлендә Бакуга килеп чыга. Кавказда зур болганышлар булу сәбәпле, көньякка үтә алмый, кире Әстерханга кайта. Кавказ буендагы бу «сәяхәтендә» ул биредә Һади Атласины, Истанбул университетында белем алган, төрле китаплары белән билгеле булган мәгърифәтче Нәҗип Гасрыйны очрата... Болар икәүләп Казанга киләләр. Г. Баттал Казанда гаиләсе белән яшерен генә очрашканнан соң төньяк-көнбатышка юл ала һәм 1921 елның июлендә, чикне яшерен үтеп, милләттәшләре ярдәмендә Финляндиягә барып чыга. Анда өч ел тора, биредә яшәүче милләттәшләребезнең балаларын укыта, Германиягә барып С. Максуди, Г. Исхакый, Ф. Туктаровлар белән очрашып кайта.

1925 елны Г. Баттал Төркиягә күчеп килеп урнаша. Финляндиядә яшәгән вакытында да фәнни эш белән шөгыльләнә. Ул заманда да, хәзер дә «татар» исеменә карата яшәп килә торган кире караш Г. Батталның да җанына тия. Финляндиядә әнә шуңа җавап бирү, ялган карашны бетерү өчен татар халкы тарихы буенча эзләнүләр алып бара. Аның бу хезмәте элек Казанда басылган «Төрек-татар тарихы»ның дәвамы буларак та карала ала. Төркиягә инде ул әзер хезмәт белән килә һәм шул ук елны (1925) аның бу хезмәте Истанбулда төрек телендә «Казан төрекләре» исеме астында аерым китап булып басылып чыга. Г. Баттал Төркиядә Идел буе, Урал, Себер татарларының монгол-татар түгел, монгол түгел, ә төрки халык булуын аңлату, пропагандалау буенча эшен туктатмый. Аның бу темага язылган махсус икенче китабы да бар. Ул «Казан төрекчәсендә атасүзләр вә дәйемнәр» исеме астында 1968 елда, авторы вафат булуга бер ел кала, Анкарада басыла. Бу китапта Казан төрекләре әйтем һәм мәкальләре белән сүзгә-сүз тиңдәш һәм тиңдәш дәрәҗәсендә булган төрек халык мәкаль һәм әйтемнәре чагыштырма «сүзлеге» бирелә. Анда ике телдә дә тиңдәш 497шәр мисал китерелгән.

Китапның ахырында «Кемне татар диләр?» дигән мәкалә урнаштырган һәм шушы мисалларга да таянып татарларның чыгышы мәсьәләсен аңлаткан. 1925 елгы «Казан төрекләре»нең 1966 елда Анкарада кабат басылуы да шул максатларга бәйләнгән. Кызганыч, әле хәзерге көндә дә төрекләрнең күбесе безне аларның патшасы Баязитны үтерүчеләр токымыннан дип карый.

Төркиягә килгән елны ук Г. Баттал Төркият институтында профессор Фуад Көпреле кул астында эшли башлый. Профессор вафат булгач аны Матбугат Гомуми Мөдирлегенә чакыралар, ул анда русчадан төрек теленә тәрҗемәләр белән шөгыльләнә. Бирeдә эшләгәндә «Русиядән аерылган милләтләр» (дәүләтләр) дигән әсәр яза, 1927 елда ул Анкарада аерым китап булып чыга. Бераздан бу Мөдирлек Тышкы эшләр Баканлыгы (Министрлыгы) белән берләштерелә, Г. Баттал да шунда күчерелә.

Төркиягә килеп урнашкач, Г. Баттал, кайда гына эшләмәсен, фәнни-тикшеренү эшләрен ташламый. Матбугатта, бигрәк тә фәнни матбугатта, төрки телләр, төрки халыклар, Казан ханлыгы, Казан төрекләре, Төркия тарихы, милли хәрәкәт мәсьәләләре буенча үзенең мәкаләләре белән актив катнашып килә. Ул—чын мәгънәсендә журналистикага да гашыйк, аңаярты гомерен биргән кеше. Россиядә вакытта аның мәкаләләре «Вакыт», «Йолдыз», «Корылтай», «Алтай», «Маяк» газеталарында, «Шура», «Ак юл», «Сөембикә», «Укытучы», «Хатын» журналларында басылып килә. Мисырда ул «Әл-Җәридә», «Әл-Мөкаддәмә», «Әл-Мәннар» газеталарында катнаша, Казанга кайткач та алар белән элемтәсен өзми.

Төркиядә аның хезмәтләре «Вакыт», «Яни сәс», «Яни Сабах», «Тасвир», «Төрек йорды», «Яни Кавкасия», «Азери төрек», «Хакимияти миллия», «Азербайҗан йорт билгесе», «Яни төркестан», «Төрек дили», «Төрек иле», «Төрек культуру», «Айын тарихы» кебек журнал вә газеталарда, Германиядә (Мюнхенда) төрек телендә чыккан «Дәрги» журналында басылганнар. (Г. Батталның бу басмалардагы хезмәтләрен барлау үзе зур көч сорый.)

Г. Баттал Төркия фән дөньясы белән дә тыгыз бәйләнештә яши. 1932 елда Истанбулда үткрелгән Беренче төрек теле корылтаенда катнаша, анда чыгтай вә госманлы телләр буенча доклад белән чыга. Г. Батталның төрек теленә караган хезмәтләренә Ататөрек тә игътибар итә, аның тәкъдиме буенча Г. Баттал якут теле сүзлеген төзүгә алына.

«Төрек дили курумы» (төрек теле җәмгыяте) соравы һәм аның планы буенча Г. Баттал «Ибн Мөханнә логате»н төзи (аерым китап булып 1934 елда Истанбулда басыла). «Бөек кыргыз сүзлеге»н хәзерли (1945 елда басыла).

1947 елда Г. Баттал пенсиягә чыга. Аның тормышында шушы вакыттан яңа иҗат чоры башлана. Пенсиядә вакытта да ул фәнни журналларда актив катнаша. Югарыда искә алынган матбагадан тыш аның пенсиядә вакытта язган хезмәтләре Голландиядә атаклы Брилл нәшриятында чыга торган «Handbuch Orientalistik» журналында, шунда ук басылган атаклы «Phylologicae Fundamenta»ның икенче томында урын ала. Болар инде турыдан-туры әдәбиятка караган, төгәлрәк әйткәндә, «Казан төрекләре әдәбияты», «Кырым төрекләре әдәбияты» исеме астында чыккан гыйльми-монографик язмалар. Аның бу хезмәтләре немец һәм француз телләрендә басылган. Шуны да искәртеп үтү кирәктер, туган теленнән тыш Г. Баттал урыс, гарәп, төрек, фарсы, немец, француз телләрен яхшы белгән, фин телен дә шактый үзләштергән, полиглот булган.

Пенсиягә чыккач, Г. Баттал иҗаты тулысынча диярлек туган халкы тарихы, аның әдәбияты, күренекле кешеләре, милләтебезнең мөкаддәс якларына таба борыла. Чит илдәге әдип, галимнәребез арасында Г. Баттал беренче булып халкыбызның олы зыялыларын торгызу эшенә керешә һәм «Мәшһүр Казан төрекләре» сериясен башлап җибәрә. Шушы сериядә ул Төркиядә төрек телендә, беренче чиратта төрекләрне таныштыру, милли рухын оныта башлаган эмигрант татарларның тарихи аңын уяту өчен халкыбызның бөек уллары турында «Ризаэтдин Фәхретдин оглы», «Галимҗан Баруди», «Муса Ярулла Биги», «Ике бертуган Максудилар» дигән китаплар бастырып чыгара. Әнә шуларның берсен төрек теленнән тәрҗемә итеп укучыларга тәкъдим итәбез. Ышанып әйтәм: бу әсәр укучыга күп яңалыклар, күп фактлар алып киләчәк, битараф калдырмаячак.

Тарихның, мәдәниятнең, иҗтимагый фикернең нигезен тәшкил итүче әдәбият була. Ул—мемуарлар. Г. Баттал да бу нәрсәне атлап үтми. Шул юнәлештә Россиядә үзе күргән, кичергән хәлләрне эченә алган «Рус ихтилалының хатирәләре» дигән истәлекләрен яза (басыла: Истанбул, 1948), «Яшел Ризә вә Или» исемле, авыр сәяхәтләрендә күргән хәлләрне тасвирлаган китабын әзерли (басыла: Анкара, 1950). 1962 елда аның киң планда эшләнгән мемуарларының беренче кисәге «Ben bir

isik Ariyordum» иceме астында (аны «Минем тәрәзәләрем» дип тәрҗемә итәргә була) Истанбулда дөнья күрә. Г. Баттал бу мемуарларын дәвам иткән, әмма язылып беткәнме, юкмы, анысы билгеле түгел. Гомумән, аның кульязма мирасын барлау турында да безгә уйланырга бик вакыт.

Аның хатыны доктор Газизә ханым иреннән соң бер ел торып вафат була. Аларның әтисе фамилиясен йөрткән Билгияр исемле улы булган. Аның исән булуы мөмкин, һәрхәлдә, аның оныклары әле дә Төркиядә яши торганнардыр диясе килә.

Г. Баттал-Таймас, ягъни укучыга тәкъдим ителә торган «Ике бертуган Максудилар» китабының авторы турында күзәтүне шуның белән төгәллик. Шушы күзәтүдән дә Г. Батталның чит илләргә барып чыккач та үз халкының язмышы, тарихы, киләчәге турында өзлексез кайгыртканлыгы, зур хезмәтләр калдырганлыгы, халкыбызның рухи мирасына зур өлеш керткән мәшһүр улы икәнлеге ачык күренә.

Габдулла Баттал-Таймас талантлы педагог һәм мәгърифәтче генә түгел, ул тарихчы, әдәбиятчы зур галим дә, талантлы тел белгече һәм сәяси эшлекле дә, журналистика өлкәсендә зур эз калдырган матбагачы, үзенең эшләре белән Гаяз Исхакый, Садри Максудилар янәшәсендә торучы милләт хадиме дә.

Дустыңның кем икәнен әйтсәң, синең кем икәнеңне белермен, дигән сүз бар. Г. Батталның дуслары, аркадашлары, танышлары, якыннары арасында Р. Фәхретдин, С. Рәмиев, М. Галәү, Г. Ибраһимов, Ф. Әмирхан, Ф. Туктар, Ә.-Г. Хәсәни, М. Корбангалиев, бертуган Шәрәфләрне санап үтү дә күп нәрсә турында сөйли. Чит илләргә барып чыккач та ул үзенең иске танышлары, дуслары, каләмдәшләре С. Максуди, Й. Акчура, Г. Исхакый, Әгъдәс Курат, Рәшид Аратлар белән бер юлдан барган.

Г. Баттал турындагы бу язманы бер теләк белән тәмамлыйсым килә. Күрәсез, чит илләрдә халкыбызның уллары тудырган нихәтле бай мирасыбыз бар икән! Г. Баттал тудырган хезмәтләрдән дә бу ачык күренә. Ул әдип, галимнәребезнең хезмәтләрен без кайчан үз укучыбызга җиткерербез? Кайчан без аларның төрле матбугат битләрендә басылган хезмәтләрен җыярга ныклап тотынырбыз? Кайчан аларның кульязма мирасын барлау, өйрәнү, туплау эшенә ныклап керешербез икән? Дөнья гаять катлаулы, соңга калмаска иде, милләттәшләр!

Әбрар Кәримуллин,
академик
1995 ел.

Г. Г. БАТТАЛ-ТАЙМАС

ИКЕ БЕРТУГАН МАКСУДИЛАР

ӘХМӘТҺАДИ
(1867—1941)

САДРИ АРСАЛ
(1879—1957)

БӘЯЛӘМӘЛӘР, ҖАВАПЛАРДАН ӨЗЕКЛӘР

(Моңа хәтле чыккан өч китап уңаеннан)[1]

Хәсән Али Юкель, мәгариф өлкәсендә эшләгән зыялы. 25 август, 1958 ел.

Китапларыгызна алдым. «Муса Ярулла»ны дикъкать белән укып чыктым. Сез искә алган әсәрләр минем китапханәмдә юк. «Заман» китапханәсендә борынгы китаплар булгалый, эзләп карадым, Сез сораганнары юк. Минем эзләнүләремнең сәбәбе үзем хөрмәт иткән мәрхүм Муса Ярулла һәм Сезнең китабыгыз турында мәкалә язарга теләгемнән. Анкарага кайтуга бу эшкә керешәчәкмен.

Сезнең хезмәтегез зур игътибарга лаек. Муса Яруллаиың эшчәнлеген искә алу һәм аның хезмәтләрен ихтирам белән файдалану заруридыр. Җавап язуда соңлавым өчен гафу үтенәм.

Мирза Бала-Кутлук, әзербәйҗан галимнәреннән. Мюнхен, 17 декабрь, 1958 ел.

«Казандагы төрек мәшһүрләре» сериясе гаять мактаулы күренеш. Бу башлангыч зур игътибарга лаеклы. «Дерги» жур-

[1] «Казан төрекләре мәшһүрләре» сериясеннән чыккан «Ризаэтдин Фәхретдин», «Муса Ярулла Биги», «Галимҗан Баруди» дигән китаплар турында сүз бара. Г. Баттал-Таймасның бу китаплары да төрек телендә, Истанбулда басылган, күрсәтелгән сериянең I, II, III китапларын тәшкил итә, ә бу «Ике бертуган Максудилар» сериянең IV китабын тәшкил итә. Бу дүртенче китап шушы өч китап турындагы «Бәяләмәләр, җаваплардан өзекләр» белән башлана (Ә. Кәримуллин искәрмәсе. Ары таба Ә. Кәримуллин искәрмәләрен Ә. К. дип кенә күрсәтәбез).

налында бу турыда бер мактау сүзе язарга җыенам. Бу нәрсәне авыру сәбәпле кайчан язып бетерә алырмын дип борчылам.

(Бу сәяси зыялы 1959 елның 8 мартында вафат булды).

Таһир Шакир Чагатай, социология фәне буенча доцент. Анкара, 27 декабрь, 1958 ел.

Һәр өч рисаләне дикъкать белән укыдым. Мин һәр өч әсәрне дә файдалы вә кирәкле саныйм. Һәр кешенең алар турында үз фикере бар. Бу аларның үзләренең карашларына, тормыш тәҗрибәсенә бәйләнгән. Мондый җитди мәсьәләләрне хис, эмоциядән чыгып бәяләү дөрес булмас. Минемчә, бу һәр өч әсәр (Ризаэтдин Фәхретдин оглы, Муса Ярулла Биги вә Галимҗан Баруди) үзләренең эчтәлеге белән уңышлы чыккан, тирән уйлап язылган. Сезнең хезмәтегез тирән рәхмәткә лаек. Сез авыр шартларда яшәүче халкыбыз турында кайгыртасыз, аларның язмышы өчен борчыласыз. Өмет итәм ки, Сез бу өлкәдә тагын зур эшләр башкарырсыз, якташларыбызның милләттәшләребез турында ничек кайгыртуы турында үрнәк булып торырсыз.

Профессор фон Габайн.
Гамбург.
(Доктор Хәмит З. Кошай язып алган).

Г. Баттал-Таймасның «Казан төрекләре мәшһүрләре» китаплары өчен зур рәхмәт. Алар минем өчен бик кызыклы, чөнки мин Казан зыялылары арасында реформалар—үзгәртеп корулар хәрәкәте турында белми идем. Бу хезмәтләр аркылы мин бу турыда шактый нәрсәләр белдем...

И. Мөһәндис Кемал Локман.
Анкара, 28 июль, 1958 ел.

Бу ике китабыгыз (Ризаэтдин Фәхретдин оглы вә Муса Ярулла Биги) безнең кебек, бала чактан ук үз илләреннән аерылганнар өчен бик файдалы. Анда халкыбызның зур галимнәре, күренекле кешеләр хакында әһәмиятле белешмәләр

китерелгән. Матбугатта һәм төрле басмаларда бу галимнәр турында кайбер нәрсәләр күренсә дә, бу китаплардагы кебек тулы материаллар юк иде. Сезнең китапларыгыз мактаулга лаеклы. Читтә яшәү аркасында материаллар табу авыр, матур вакытлар җиткәч тулырак язылыр дип көтеп тору килешә торган хәл түгел.

Имам Вәли-Әхмәд Хәким.
Хельсинки, 10 август, 1958 ел.

Газизем, Таймас Бәй, мәрхүм Муса Ярулла хакында язган гүзәл әсәрегезне укыдым. Мәрхүм остазны ихтирам итеп, иҗтимагый эшләрен тәкъдим итеп, гүзәл фикерләрен, гүзәл сүзләрен кабул итеп, аңлатып бер рисалә язып гаять зур ихтирам казандыгыз. Мәҗмугалар, вакытлы матбугатта язылган мәкаләләр югалып кала. Аерым китап булып басылгач әсәр һичбер вакыт югалмый, кешеләр яшәгәндә алар белән яши.

Остаз, бәрәкәтле каләмегез белән бу рисаләне язып мәрхүм вә мәгъфүр останы тергездегез. Үз вакытында мәрхүмнең тәрҗемәи хәлен язып таратмак түгел, аның гаиләсенең исән-саумы икәнен белүче дә юктыр.

Казанлы төрек мәшһүрләреннән галим Ризаэтдин хәзрәтләрнең тәрҗемәи хәле, башкарган хезмәтләре турында сөенеп укыдым. Бик яраттым, бик файдаландым.

Остаз Галимҗан Баруди турында язган кыйммәтле китапны да алдык, укыдык, яраттык. Ул үзенең 35 елдан артык гомерен үзенә шәкертләр тәрбияләүгә багышлаган булса да, аның бер шәкерте дә үзенең остазының тормыш тарихын, фәнни вә рухи эшләрен тулысынча ачып, язып биргәне булмады. Бу бөек дини, иҗтимагый хезмәтләрне тәкъдир кылып гүзәл бер тәрҗемәи хәлен язу җиңел эш түгел. Бу эшне Сез башкаргансыз. Моның өчен Сезгә чын рәхмәт, кадерле остаз!

Имам Хәбибрахман Шакир.
Тампере (Финляндия). 20 июль, 1959 ел.

Халидә туташ Вафа тарафыннан миңа «Муса Ярулла» вә «Ризаэтдин Фәхретдин оглы» исемле ике әсәр бүләк буларак тапшырылды. Бу әсәрләрне укып чыккач Сезгә ихлас күңелемнән рәхмәтләремне белдерәм. Сәламәт булыгыз, киләчәктә

тагын шундый әсәрләрне мәйданга чыгарырга муафыйкъ булсын. Муса Ярулла хакындагы әсәрегез мине артыгы белән сөендерде. Чөнки мин үзем дә Муса Яруллаиың шәкертләреннән, аның эшен дәвам итүчеләрдән. Мәрхүмнең Һиндстандагы тормыш дәвере дә минем күз алдымда узды. Бу яктан да миндә күп мәгълүмат бар.

Профессор Б. Шпулер.
Гамбург, 24 ноябрь, 1958 ел.

Миңа күндерелгән ике кыйммәтле китаплар өчен бик зур рәхмәт. Татар вә башкортларның рус хакимияте астында яшәве турында китап язган кеше буларак, бу әсәрләрдәге мәсьәләләр мине бик кызыксындыра. Шуңа күрә бу ике китапны бик кызыксынып укыячакмын.

Профессор Матти Ресенен.
Хельсинки, 9 февраль, 1959 ел.

Чук хөрмәтле аркадашым Габдулла Б.-Т. Күндерелгән китаплардан «Казан төрекләре мәшһүрләре»ннән 1—3 китаплар өчен чук рәхмәтләремне белдерәм. Бу сериядә хезмәтләрегезнең яңалары дәвам итүен телим.

Зухур Таһир. Төрек-ислам җәмгыятенең рәисе.
Хельсинки, 1 август, 1958 ел.

Күндерелгән «Муса Ярулла» китабын алдым. Зур рәхмәт Сезгә. Китабыгызны дикъкать илә укыдым, бик мәмнүн булдым. Муса әфәнденең тәрҗемәи хәлен тулы язгансыз. Әсәрләрегез белән якын арада биредәгеләрне дә таныштырачакмын...

Доктор Хәмит З. Кошай.
Анкара, 5 декабрь, 1958 ел.

«Галимҗан Баруди» китабын игътибар белән укыдым. Хезмәтегез кабул булсын! Бу китапны язып Сез галимгә зур хөрмәт күрсәтәсез.

Сами Н. Өзәрдим, Милли китапханә мөдире.
Анкара, 15 январь, 1959 ел.

Өч биографик әсәрегез турында «Төрек дили» журналының үткән санында мин библиографик белешмә урнаштырдым. Гафу итәрсез, бу өлкәдә мин бу хәтле хәбәрдар түгел, танытмаларымның кыска, тулы булмавы бар. Мин Сезнең китаплар белән укучыны таныштыру йөзеннән чыгып кына эш иттем. Гафу итәрсез.

А. Беннигсен.
Париж, 3 октябрь, 1958 ел.

Истанбулдан Сезнең ике әһәмиятле «Ризаэтдин Фәхретдин оглы» һәм «Муса Ярулла Биги» дигән монографияләрегезне алдым. Кызганыч, китап кибетләрендә Сезнең «Галимҗан Баруди», «Ике бертуган Максудилар», шулай ук элек басылган «Казан төрекләре» (Истанбул, 1925), «Рус иһтилаленнән хатирәләр» (Истанбул, 1947), «Россиядән аерылган милләтләр» (Анкара, 1927) һәм «Төрек-татар тарихы»н (Мукден, 1938) таба алмадым. Бу минем өчен бик кызганыч, алар минем фәнни тикшеренүләрем өчен гаять кирәк хезмәтләр.

Халидә Вафа.
Тампере (Финляндия), 2 июль, 1958 ел.

Бу кыйммәтле китапларны укып чыгуга ук аларны яшьләргә тәкъдим иттем. Милләт юлында, динемездә яшәүчеләр аларны бик яратып каршыладылар. Әсәрләрнең теле госманлы булганга әсәрләрнең эчтәлеген тирәнрәк аңлау өчен ул китапларны кайта-кайта укыйлар, укыган саен аларны югары бәялиләр. Мин Тампере Төрекләр берлеге очрашуларында бу китаплар турында мөмкин хәтле киңрәк аңлатырга дип торам.

Хәмит Рәшит.
Нью-Йорк, 27 декабрь, 1958 ел.

Халкыбыз өчен зур хезмәтләр күрсәткән бөек кешеләребез турында китаплар язып чыгаруыгыз Сезнең зур хезмәте-

гездер. Аллаһы тәгалә Сезгә саулык, бәхет һәм озак гомерләр насыйп итсен.

Укытучы Габдерәхим Уйгур Озынтөрек.
Кула, 15 март, 1959 ел.

Мөхтәрәм остазым, әсәрләрегез нәшер ителү уңае белән котлыйм. Әсәрләрегезне бик зәвыкланып укыйм. Бу кирәкле хезмәтегезне дәвам итүегез өчен Олы Тәңредән Сезгә озын гомерләр вә нык саулыклар сорыйм.

Азим Зиһниоглы (Тәкәлләрдән).
Истанбул, 3 апрель, 1959 ел.

Сезнең өч китабыгызны теләп алдым. Дәвамлы хезмәтегез, башкарган уңышлы эшләрегез белән чын күңелдән тәбрик итәм.

Рәфикъ Үздәк, хокукчы—юрист.
Истанбул. 16 декабрь, 1958 ел.

Ике кыйммәтле китабыгызны сөенеп алдым. Милли тәрбиядә хезмәт итү өчен бөек кешеләребезне белү, аларның тормыш юллары белән танышу бик кирәкле шәйдер. Моннан соң да чыгачак әсәрләрегездә хәзерге вакытта төньяк туганнарыбызның мәдәнияты һәм сәнгате турында мәгълүматлар укырга теләр идем, шул өметләр белән калам. Тырышып, уңышлы эшләвегез сөендерә, йөрәгемнән Сезгә эшегездә уңышлар теләп калам.

Лотфи Икиз, китапханәче.
Нәүшәһәр, 8 июнь, 1959 ел.

Басылып чыккан кыйммәтле китапларыгызны укыдым. Сезне тәбрик итәм. Киләчәктә Сезгә яңа хезмәтләр язарга Җәнаби-Һактан ярдәм итүен сорыйм. Сезнең эшләрегез үлемсез хезмәтләр алар...

Габделкадыйр Инан, Төрек оешмасы белгечләреннән. Анкара, 31 июль, 1959 ел.

Мөхтәрәм Г. Баттал ага-бәйем.

Миңа күндерелгән ике китабыгызны алдым. Бик күп рәхмәт Сезгә. Гүзәл бер милли хезмәт бирүегез белән Сезне тәбрик итәм вә Тәңредән бу эшне уңышлы дәвам итүдә Сезгә ярдәмен үтенәм. Милли культурабызның хадимнәрен Сез күтәреп чыккансыз, аларны таныткансыз. 40 ел буенча «большевикларның авыр золымында» безнең милләтебез хокуксыз яши, җәбер ителә, дип килү белән чикләндек. Сез бик файдалы эш башладыгыз, Сезнең матди фидакарьлегегез дә тәкъдир ителергә тиеш. Бу эшне Сез бер тиен матди файда алмыйча башкарасыз.

Сезне кабат котлыйм вә рәхмәтләремне җибәрәм.

КЕРЕШ

Казан иленең Казан арты[1] дигән ягындагы Ташсу авылы имамы Низаметдин Максудиның өч улы була: Әхмәтһади, Сәлахетдин һәм Садретдин. Аларның өлкәне Ә.-Һади, иң кечесе Садретдин (Садри) Максудилар—Казан төркләренең фикери һәм мәдәни тормышында күренекле роль уйнаган фикер ияләре. Уртанчылары—Сәлахетдин—озын буйлы булып, укуга бирелми, эш дөньясына кереп китә һәм Казан шәһәренең Печән базарында күн товарлары кибете ачып, сәүдә эшенә керешә. Биредә безне боларның олысы һәм кечесе—ике Максуди кызыксындыра.

Кече кардәшләренең шөһрәте шактый өстен һәм билгеле булганга, без биредә сүзне яшь өстенлеге ягыннан түгел, кече туганнарының тормышы һәм эшчәнлеген тасвирлаудан башлыйбыз.

Олы туганы тәрбияче-педагог һәм журналист-газетачы иде. Ул оста педагог һәм дәреслекләр авторы буларак дан алды. Кече туган исә зур сәяси эшлекле буларак танылды. Русиядән киткәч, кырык яшьләре тирәсендә фәнни эшчәнлек белән шөгыльләнә башлады. Сәясәттәге кебек бу өлкәдә дә зур хезмәтләр башкарды, бу яктан да абыйсын узып китте. Ул үзенең өлгергәнлеге, хәзерлеге, белеме ягыннан да өстенрәк иде.

Төркиягә килеп чыккач, үзенең белемен һәм фәнни эшчәнлеген җәелдерү өчен биредәге—яңа илдәге шактый уңай

---

[1] Казан шәһәренең төньягындагы җирләргә урнашкан төрек авылларын казанлылар «Казан арты» дип йөртәләр. Менә шуңа күрә дә казанлы шагыйрь Г. Тукай үзенең бер шигырендә болай дип язган:

Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,
И, Казан арты! Сиңа кайттым сөеп тагын да мин.

Шагыйрьнең туган авылы Кушлавыч та Казан артында булмактыр. (Г. Баттал искәрмәсе. Ары таба аның искәрмәләрен Г. Б. дип кенә күрсәтәбез.)

шартларга тап булды. Садри Максуди Төркиядә, сәясәтче булуга караганда, күбрәк Төркия дәүләтен ныгыту буенча мәгърифәтче вазифасын үти, үзенең киңәшләре, фикерләре һәм фәнни эзләнүләре белән төрек халкына хезмәт итә, файдалы эшләр башкара. Биредә ул сәяси эшләрдән читләшә. «Русия вә Сибирия төрек халыкларының сәяси таләпләре» дигән мәсьәлә буенча Аурупада башлап җибәргән «проблема»ны да оныта. Бәлки онытмагандыр да, бәлки моңа вакыты булмагандыр. Ничек кенә булмасын, аның Франциядән Төркиягә килүе тормышында зур вакыйга булып тора. Бу газиз йортка чакыруны ул бервакытта да онытмас. Бирегә килү аның иҗади вә фәнни эшчәнлеге өчен зур мөмкинлекләргә юл ачты.

Большевиклар дәверендә Казанда аерылып калган абыйсының—Әхмәтһади Максудиның эшчәнлеге һәм тормышы өчен шартларның җиңел булмавы үзеннән-үзе аңлашыла. Ул совет дәверендә журналистика һәм педагогика өлкәсендә эшли алмады. Большевиклар дәверендә ул публицистикадан ераклашты, аның элек язган мәктәп китаплары да читкә этәрелде. Моңа капма-каршы буларак, кече энесе фикер һәм фәнни иҗат ягыннан үсә барды, тормыш һәм матди яктан да авырлык һәм җитешсезлекләрне белмәде. Кыскасы, советлар җирлегендә өлкән абыйсының иҗади эшчәнлеге туктап калды, шуның өстенә ул матди яктан гаять авыр хәлдә яшәде. Аның соңгы 23—24 еллык гомере өзлексез куркынулар астында үтә. Көчле акыл иясе булган бу кеше совет чорында кешеләргә яңа фәнни хезмәтләр бирә алмыйча, бәхетсезлеккә төшеп күзләрен йомды. Әхмәтһади әфәнде, гаять сак кеше буларак, совет шартларында кулга алынмыйча, төрмәгә ябылмыйча кала алды. Моның өчен аңа Совет власте чорында милләтебезнең изге эшенә хезмәт итүдән читләшергә туры килде. (Бу язманың «Б» бүлеген карагыз.)

Садри Максудиның тормыш юлы, фәлсәфи-иҗтимагый карашлары турында сүз башлау үзмаксат түгел. Кыскача шуны әйтә алабыз: мәрхүм тормышка аек карашлы төрекчемилләтче иде. Үзенең мәкаләләрендә, лекцияләрендә, конференцияләрдәге чыгышларында милли гамәлләргә карата күп тукталды. Сәяси, икътисади мәсьәләләрдә либераллар тарафдары булды. Социализмны кабул итмәде. Карл Марксны, социолог-философ буларак таныган хәлдә, аның сыйнфый яңа җәмгыять төзү теориясен кабул итмәде, сыйнфый көрәш мәсьәләсе дә аны җәлеп итмәде. Бөек якташыбыз С. Максу-

ди, Йосыф Акчурадан аермалы буларак, кешелек тарихында социаль факторларның хәлиткеч ролен дә танымады, киресенчә, фикерләр, идеяләр, бөек шәхесләрнең кешелек тарихында зур роль уйнавына басым ясады. (Моны аның төрек тарихы буенча үткәрелгән беренче конференциядә ясаган «Тарихның гамәлләре» дигән чыгышыннан күреп була.)

Дәүләт белән идарә итү мәсьәләсендә дә С. Максуди 1917 елгы революция тарафдарлары ягында түгел иде. Тора-бара аның карашлары киңәя һәм ул соңыннан демократик-республикачылар ягына чыга. Үзенең рухы һәм хисе белән аристократ булган С. Максудиның демократлыгы теоретик дәрәҗәдән узмый. Ул демоска кушылып, аның теләк һәм хыяллары белән яшәгән, кирәк икән, аның өчен гомерен дә бирергә әзер торган шәхес, Ширазлы хәким Сәгъди әйткәнчә, күләгәдә калып яшәргә яраткан демократ булмый.

Монда бер философның бер китапта язылган сүзләре искә төшә: «Асылда мин социализм яклы. Ләкин мин ул режимда яшәргә теләмәс идем, андый хәятнең миннән соң килүе хәерле булсын». (Бу—бер француз короле сүзе.)

Мәрхүмнең характеры кырысрак, шуңа карамастан ул гадел кеше иде. Табигате белән ул өлкән абыйсына охшаган. Алар икесе дә сәер тоела торган гамәлләр һәм уйларга бирелә иделәр. Безнең бер якташыбыз юкка гына: «Һади әфәнде ул—кырынмаган Садри, ә Садри бәй—кырынган Һади ул»,—димәгән.

Садри Максуди шактый һавалы, бик тиз кабынучан кеше була. Уен-көлкене кабул итмәгән, ләкин күңелендә кешегә ачу, үпкә сакламаган. Моны раслый торган бер мисал китерик. Яшь вакытлардан дусты булган язучы Гаяз Исхакый белән газетчы-журналист Фуат Туктар 1905 елгы революция елларыннан башлап 1917 елгы инкыйлабка хәтле аның турында матбугатта авыр сүзләр әйтүдән тартынмадылар. 1917 елгы революциядән соң алар үзара аңлашалар, килешәләр, якынлашалар. Ә соңгысы белән Аурупада оештырылган «Солых һәйәте»ндә бергә эшлиләр.

Мәрхүм җәмәгать, милләт өлкәсендәге эшләрне үзенең шәхси мәнфәгатьләреннән өстен куя алды.

1946 елның 18 февралендә Истанбулдан Анкарага—миңа язган бер хатында ул үзенең бу характерын аңлатып болай язган иде: «Моның ике сәбәбе бардыр. Берсе әхлакый бер канаттыр: кешенең кечкенә, вак җитешсезлекләре вә йомшаклыгын күрмәскә, аңа игътибар итмәскә кирәк. Бу—кешенең

әхлакый нигезе. Ә икенчесе—бер психологик сәбәптер...» (Бу сүзләрне ул миңа, безнең арадагы мөнәсәбәтләрне ачыклау йөзеннән язган иде. Бу психологик сәбәпләр уңаеннан миңа күп җылы, хуш сүзләр әйтелгән иде. Аларны биредә китермәскә булдым.)

«Табигатем шулай булырга кирәк: мин бер кешегә дә дошманлык хисе сакламыйм»,—дип сөйләр иде. Шул ук вакытта: «Аның самими, чын күңелдән якын күргән дусты булды микән?»—дигән сорау да туа.

Аның белән бәхәс итү, бер яктан, бик күңелле, кызык булса, икенче яктан, авыр, читен була иде. Чөнки ул күп укыган, тирән эрудицияле, дөньяны күп күргән, зур гыйлем иясе иде. Авыр иде шуның өчен: ул үзенең эрудициясе белән бәхәсне үзе теләгән якка бора, аның дәлилләре алдында югалып каласың, әгәр аның белән үзсүзләнеп бәхәсләшә башласаң, кыза башлый иде. Шундый бер халәткә мин дә шаһит булдым. Анкараның Яңашәһәр районындагы «Өзән» кондитерханәсендә сөйләшеп утырганда ул минемниндидер сүземә ачуланып: «Сез һәрчак миңа каршы киләсез»,—диде дә үпкәләп чыгып китте. Әйе, ул хаклы түгел иде. Минем аның белән бервакытта да үпкәләшкәнем булмады. Аның турында бервакытта да кире караштa булганым юк. Бердәнбер хәл—мин аны һичбер заман күккә чөеп мактамадым, бары шул гына.

Бу очрашуда ул үзенең кызып китүен аңлады булса кирәк. Шушы вакыйгадан соң без күп тапкырлар очраштык, аралаштык. Бу да аның эчкерсез кеше, ачу сакламый торган кеше икәнен күрсәтә.

С. Максуди асылда мәһабәт гәүдәле, күзгә ташлана торган кеше иде. Сау-сәламәт, авырмый иде. Олыгая барган көннәрендә генә аның эчке әгъзалары авырта, нервылары какшый башлады. Анкарада яшәгән елларда ара-тирә каты авыргалап та алгалады.

Дәвалаучы докторлар Садриның бу хәле турында аның якыннарына әйтсәләр дә, бу турыда ул үзе бер сүз әйтмәс иде, үзен таза, сау-сәламәт кеше итеп күрсәтергә тырыша иде. Вафатына өч-биш ел кала ул ашказаны асты бизе (панкреатит) белән бик каты авырый, Истанбулның бер хастаханәсендә ятып та чыга. Авыру булуына карамастан, дәүләт эшеннән киткәннән соң да иҗат эше белән шөгыльләнүен дәвам итә, күп укый, күп яза. Үзен: «Мин журналист түгел»,—дип санаса да, Истанбулның Османбәй районы ша-

гыйрь Нигар урамында нәшер ителә торган «Тасвир» газетасына мәкаләләр юллап тора. Ул үзенең исеме югалуын теләми, кешеләр хәтерендә яшисе килә, шуңа күрә олы яшендә дә эшләвен, язуын дәвам итә.

Пенсиягә чыгып, биш ел чамасы ял иткәннән соң, С. Максуди 1950 елда Демократик партия исеменнән Төркия Милли Мәҗлесенә депутатлыкка кандидат итеп Анкара сайлау округы буенча үзен тәкъдим итә. Сайлау кампаниясенә әзерлек уңаеннан Төркиянең төрле районнарына сайлаучылар белән очрашуларга барып йөри, үзенең программасын аңлата. Мин аның бу очрашуларның берсеннән бик арып кайтуын бүген дә хәтерлим.

Ул чакта аңа инде 75 яшь иде, 1954 елда ул тагын шундый сайлауга яңадан үзенең кандидатурасын тәкъдим итә, ләкин бу юлы да С. Максуди сайлау исемлегенә үтми кала. Гомеренең калган 5—7 елын ул яңа хезмәтләр язу һәм аларны бастыру эшләре белән яши.

Казанлы бу ике мәшһүр кардәшләрне мин якыннан белә идем. Миңа аларның тормышлары да, иҗтимагый-сәяси карашлары да, югары әхлаклы затлар булуы да бик яхшы билгеле иде. Өлкәне белән мин дүрт ел буе бергә эшләдем, аның холык-фигылен, уй-фикерен дә өйрәндем. Кечесе—С. Максуди белән 1913 елда Казанда таныштым. Аның Троицкидан—Урал ягыннан Казанга кайткан чагы иде. Ул вакытта С. Максуди Дәүләт Думасы депутаты түгел иде инде, Казанда адвокат булып эшләгән вакытлары иде.

Абыйсы Ә.-Һади Максуди чыгара торган «Йолдыз» газетасында эшләгән заманда С. Максуди газета редакциясенә килгәли иде, шунда без аның белән очраша, төрле мәсьәләләр турында сөйләшә торган идек. Безнең очрашулар 1917 елгы революциягә хәтле шулай дәвам итте. Революция булу белән ул мәркәзгә китте, кадетлар—демократик конституциячеләр партиясе әгъзасы буларак, бу партиянең эшчәнлегендә, аның съездларында актив катнаша башлады. Шушы партиянең вәкиле буларак, ул «Төркестан комитеты» эшен оештыру буенча Ташкентка китте. 1917 елның язында Казандагы Милли Шура оешмасы да аны Ташкентка үзенең вәкиле итеп тәкъдим иткән иде. Ташкентта чагында да, 1917 елның июлендә Казанда үткәрелгән Русия мөселманнары съездында да, Уфада «Эчке Русия вә Сибирия төрек-татарлары мәҗлесе» оештырган җыелышларда да, Совет хөкүмәте Милли идарәне тараткач Казанда да без тыгыз элемтәдә булдык. 1918 елның

язында Казанда аерылыштык. Бу Русиядә безнең соңгы очрашуыбыз булды. Русиядән тыш без 1922 елда Финляндиядә, 1923 елда Берлинда очраштык. Бу—Аурупада безнең соңгы очрашуларыбыз булды. Аннан соңгы очрашулар турында бу китапта сүз алда булыр.

С. Максуди Төркиягә 1925 елның июнь аенда бөтенләйгә күчеп килде. Шушы елның ноябрендә мин дә Финляндиядән Төркиягә килеп яши башладым. 1927 елны без Анкарада очраштык. С. Максуди 1943 елда Истанбулга университетка эшкә урнашырга күчеп килгәнче, Анкарада 15 ел яшәү чорыбызда без шактый очрашып, күрешеп яшәдек, гаиләләребез белән дә бер-беребезгә йөрештек. Истанбулдан Анкарага килеп чыккан саен ул безнең белән күрешергә, хәл-әхвәл белешергә керми калмый иде. Ун елдан соң, 1953 елда без дә Истанбулга күчеп киттек, С. Максудилар белән бер шәһәрдә яши башладык. Биредә дә без очрашып, аралашып яшәдек.

Кыскасы, безнең арада зур дуслык булмаса да, җәмгыятьтәге, фәндә, эшебездә, тормышыбызда аермалыклар булса да, очрашу, фикер алышу, аралашу сукмакларына бервакытта да чирәм үсмәде.

«Кереш» өлешкә йомгак ясап шуны уйтер идем: бертуган Максудиларның икесе дә—Казан төрекләре арасыннан чыккан мәшһүр зыялыларыбыз. Берсе мәктәпләр өчен дәреслекләр язып һәм «Йолдыз» газетасының нәшире вә мөхәррире, журналист булып зур эшләр башкарса, икенчесе Русия парламенты—Дәүләт Думасы трибунасыннан Казан төрекләре вә Көнчыгыш төрекләренең хокуклары, гаделлек турында кыю чыгышлар ясап, аларның тулы хокуклыгы өчен көрәшкән мәшһүр зат.

С. Максуди Төркиядә дә үзенең лекцияләре, публицистик чыгышлары, төрки халыкларның тарихы һәм башка фәнни хезмәтләре белән Төркия укучылары, җәмәгатьчелек алдында зур хөрмәт казанган мәшһүр шәхесләрнең берсе. (Бу турыда китапның «А» бүлегенең III өлешендәге материалларны карарсыз.)

Ике зур шәхес турындагы бу китап, аларның иҗаты һәм басылган хезмәтләренә объектив бәя бирү белән бергә, аларның тормышы һәм хезмәтләре белән киңрәк танышырга теләгән кешеләргә ярдәм итү йөзеннән язылды.

Габдулла Баттал-Таймас.
Кадыкөй—Истанбул,
1959 ел, 1 сентябрь.

А

САДРИ МАКСУДИ АРСАЛ[1]

С. Максуди Истанбул университетының хокук факультетында эшләгәннән соң пенсиягә чыгып берничә ел яшәгәч, 1957 елның 20 февралендә 21 сәгать 30 минутта Истанбулның Гураба хастаханәсендә мәңгегә күзен йома. Ул, инде әйтеп үткәнчә, Казан йортының Ташсу авылында имам гаиләсендә 1879 мы, әллә 1880 елдамы дөньяга килә[2]. Күренекле фикер иясе һәм сәяси эшлекле, 78 нче яшендә дөньядан киткән бу зыялының тәрҗемәи хәле белән якынрак тынышыйк.

МӘДРӘСӘ ВӘ ШКОЛА

Олы абыйсы Әхмәтһади Максудиның Казанның Күл Буе мәдрәсәсенә укырга керүе турында алда киңрәк тукталырбыз. 8—9 яшьлек. Садретдинны әтисе шул ук мәдрәсәгә илтә, биредә ул 8 ел буе гарәп теленнән һәм ислам дине турында сабаклар ала. Бу вакытта аның абыйсы Кырымда, Бакчасарайда, Зинҗерлә мәдрәсәсендә мөгаллимлек итә башлаган була. Садретдин абыйсы укыта торган бу мәдрәсәгә барып бер ел

---

[1] Бу язманың Садри Максудига караган өлеше аның вафатыннан соң Мюнхенда «Dergi» («Журнал») исемле төрек телендә чыга торган журналның 1957 елгы 9 нчы санында басылды. Биредә ул вариант тулыландырып китерелә. «Dergi»дә басылган вариант ике елдан соң инглиз теленә тәрҗемә ителеп Мюнхенда ук чыга торган «The East Turkisch Review» журналының 1959 елгы 2 нче санында кабат дөнья күрде. Әхмәтһади турындагы өлеше биредә беренче мәртәбә асыла.—Г. Б.

[2] Минемчә, С. Максуди 1880 елда туган булса кирәк. Ә Парижда чыккан «Les Penseurs de l'Islam» дигән җыентыкта барон Carra de Vaux С. Максуди 1879 елда туган дип күрсәтә (1926, том 5.—Б. 404—408). Кызы Адилә Аида әтисенең 1879 елда тууын күрсәтә (Кара: Adile Ayda. Sadri Maksudi Arsal.—Анкара, 1991.—Б. 9.).—Ә. К.

укый, рус телен өйрәнә. (Бу мәдрәсәдә, башкалардан аермалы буларак, рус телен дә укытканнар.)

1872 елда Казанда хөкүмәт тарафыннан яңа типтагы Русско-татарская учительская школа ачыла. Аның максаты башлангыч татар мәктәпләре өчен рус теле укытучылары әзерләү була. Рус телен тирәнрәк үзләштерү, дөньяви гыйлемнәр эстәү өчен Садретдин 1897 елда шушы школага укырга керә. Икенче елда—1998 дә—бу школага Күл Буе мәдрәсәсе шәкерте Гаяз Исхакый да килә. Белемгә һәвәслеге белән аерылып торган бу яшь егетләр яратып Каюм Насыйри әсәрләрен, дөньяви татар китапларын су кебек эчәләр, Истанбулда басылган китапларны да калдырмыйлар һәм школага килгәч, атаклы рус язучыларының роман, хикәяләренә тотыналар һәм тиздән аларның үзләренең дә язучы буласы, хикәя, романнар язасылары килү теләге көчәя һәм школада укыганда төрекчә (татарча) беренче әсәрләрен язып та карыйлар, ул әсәрләр 1889—1890 елларда аерым китаплар булып басылып та чыга.

«МӘГЫЙШӘТ» ХИКӘЯСЕ

Бу—Садретдинның Русско-татарская школада уку елларында язган беренче әсәре. Анда үсеп килүче Казан төрек урта сыйныфы—буржуазия тормышы сурәтләнә. Әсәр, авторның үзе әйтүе буенча, «саф Казан шивәсендә язылган» беренче милли хикәя. (Бу турыда автор повестьның 1914 елда чыккан кабат басмасында искә алып үтә.)

Аның аркадашы Гаяз Исхакый соңыннан романнар, пьесалар яза башлый, күренекле язучы булып китә, ә С. Максудиның әдәби эшчәнлеге шушы хикәясе белән тәмамлана.

ШКОЛАДАН СОҢ

С. Максуди школаны 1901 елда, ә Гаяз Исхакый 1902 елда тәмамлыйлар, икесе дә башлангыч мәктәптә рус теле укытуга хокук бирә торган дипломнар алып чыгалар. Ләкин алар икесе дә бу юл белән китмиләр, рус теле укытучысы булу юлына басмыйлар. Аларның максаты—үз белемнәрен үстерү, «милләткә хезмәт итү». Дөрес, Гаяз Исхакый, школаны тәмамлагач, башта ысулы җәдид мәктәбендә укытучы булып эшли, шул ук вакытта аны авылның имамы итеп тә сайлап куялар. 1905 елгы революция башлануга ул, имамлыгын ташлап, милләткә хезмәт итү юлына баса, сул сәясәтче, журналист-

публицист булып китә. Милли азатлык юлын сайлаган Гаяз Исхакыйны патша ялчылары кулга ала, төрмәләргә яба, сөргеннәргә сөрә. Тиз арада ул танылган көрәшче-сәясәтчегә, «милләт хадименә» әйләнә, әдәби иҗат эшен дә дәвам итә, дистәләгән милли хикәя, роман, пьесалар яза... Ә аның сабакташы Садретдин Максуди икенче юлдан китә. Хәзер аның тормыш юлы белән танышыйк.

ПАРИЖДА

Кулында университетка керергә юл ача торган дипломы булган Садри Максуди белемен күтәрү өчен икенче юлдан китә. Русиядә түгел, Аурупада яисә Төркиядә укуны хуш күрә. Күрәсең, Кырымда вакытта Садретдинга Франциянең Сорбонна университетында белем алган Исмәгыйль бәй Гаспралы яисә абыйсы Әхмәтһади Максуди киңәш иткән булуы мөмкин[1].

1901 елда С. Максуди Истанбулга килә, аннан Парижга юл тота. Хокук факультетына укырга керү өчен биредә елга якын француз һәм латин телләрен тырышып өйрәнә. Ә инде 1902 елның ноябрендә ул Сорбонна университетының хокук факультеты студенты булуга ирешә.

С. Максуди Парижда дүрт ел шушы университетта укый, Кырымдагы «Тәрҗемән» газетасы битләрендә аның Парижда язган мәкаләләре басылып тора.

С. Максудиның миңа язган хатларыннан күренгәнчә, Сорбоннада уку елларында ул аның әдәбият факультетында да лекцияләр тыңлаган, шуның өстенә College de France исемле югары уку йортында да параллель ревештә белем алган.

Ул Парижда укыган елларда биредә Яхъя Кемал Байатлы исемле атаклы төрек шагыйре дә яшәгән. Бу шагыйрь Адилә Аидага: «Моннан кырык-кырык бер ел элек мин Парижда Сезнең әтиегез белән танышкан идем. Әтиегез хокук факультеты студенты иде, аның бик тырыш студент икәнен хәтерлим. Шул заманнарда ук инде күп нәрсәләр белән кы-

---

[1] Садри Максуди үзенең 1914 елда Казанда чыккан «Англиягә сәяхәт» дигән китабында Учительская школада укыган вакытында француз әдәбияты, философлары хезмәтләре белән мавыгуын, француз культурасы, әдәбиятының аңа зур тәэсире булуын искә ала. Школада вакытта ук ул үзлегеннән француз телен өйрәнүгә керешә. Күрәсең, шул вакытта ук ул инде Франциягә барып белем алу турында уйлый башлаган булса кирәк.—Ә. К.

зыксына, эзләнә торган тирән фикерле егет иде. Безнең эшләребез төрле өлкәләргә карый иде. Садри бигрәк тә социологик проблемалар белән кызыксына иде»,—дип сөйләгән.

КАЙТУ

Беренче Русия революциясе көннәрендә, 1906 елда Садри Максуди Казанга кайта һәм сәяси, иҗтимагый эшкә актив катнаша башлый. Алга таба без аның бу өлкәдәге эшчәнлегенә киңрәк тукталырбыз. Аның иҗтимагый, сәяси эшчәнлеге ике чорга бүленә. Беренчесе—Русиядәге эшчәнлеге, ә икенчесе—Русиядән тышта, бигрәк тә Төркиядәге эшчәнлеге.

Аның ике урыс революциясе арасында Русиядә 1906—1917 еллардагы эшчәнлеген яктыртуда Садри Максудиның миңа сөйләгән, аның үзеннән алган материаллар, шулай ук вакытлы матбугатта басылган чыгышлары файдаланылды. Шунысын да искәртеп үтәргә кирәктер, аның Русиядәге эшчәнлеге нигездә сәяси сферага караса, Русиядән читтәгесе—фән өлкәсенә күбрәк карый.

РУСИЯДӘГЕ ЭШЧӘНЛЕГЕ

ДӘҮЛӘТ ДУМАСЫ ВӘ САДРИ МАКСУДИ

Инде искә алып үткәнчә, ул Русиягә Париждан беренче Русия революциясе башлангач кайтып төште. Илдә конституцион режим игълан ителгән вә Русиядә яңа парламент идарәсе—Дәүләт Думасы оештырылган вакыт. Беренче Дәүләт Думасының гомере кыска булды, ул 1906 елның 27 апрелендә (10 майда) ачыла, нибары 2 ай 10 көн генә эшләп кала. Дума эшчәнлегеннән риза булмаган патша хөкүмәте аны 1906 елның 21 июлендә яба. Икенче Дума исә 1907 елның март аенда ачыла. Бу Думага депутат итеп Садри Максуди да сайлана. Алай гына да түгел, Думаның бер җитәкче комитетына да кертелә, Думаны ул мөселман халыкларының авыр шартларда яшәвен, хокуксызлыгын фаш итү өчен файдаланып, зур эшләргә керешә башлый, ләкин бу Икенче Думаның да гомере кыска булып чыга—эшли башлавына өч ай 12 көн үткәч, патша хөкүмәте 1907 елның 3 (16) июнендә монысын да куалап тарата. Өченче Думага депутатлар сайлау буенча яңа тәртипләр кертелә. Яңа закон буенча, Русиянең колониаль регион халыклары, шул исәптән Төркестанның төньяк һәм көньяк-көнчыгышында яшәүче мөселманнар сайлау хокукларыннан тулысынча мәхрүм ителә, шулай ук Кавказ мөселманнарының сайлау хокуклары нык чикләнә. Казан һәм Урал буе мөселманнарына бу регионнарда яшәүче руслар белән бергә сайлау хокукы бирелсә дә, беренчеләренең хокуклары шактый чикләнгән иде. 1907 елның 14 ноябрендә ачылган Өченче Дәүләт Думасында Идел буе һәм Урал ягы мөселманнарыннан берничә депутат булды, шуларның берсе Садри Максуди иде.

Махсус империячел максатларны күздә тотып кабул ителгән сайлау законы буенча Думага үткән депутатларның

абсолют күпчелеге шовинистик рус милләтчеләре һәм аларга якын торган октябристлардан тора иде. Менә шуның нәтиҗәсендә бу Дума «уңышлы» гына биш ел буе эшләп килде.

Оппозицион группаларның депутатлары аз, көчсез булуы аркасында, алар үзләренең тәкъдимнәрен Дума аркылы үткәрә алмадылар, аларның эшчәнлеге хөкүмәтнең, Думаның сәясәттә, икътисадта тоткан юлын трибунадан тәнкыйть итүдән узмады. Мөселман фракциясенең иң актив әгъзасы булган Садри Максуди патша хөкүмәтенең эчке һәм тышкы политикасын кискен тәнкыйть иткән чыгышлар ясаса да, бу мәсьәләләр буенча Дума бернәрсә дә эшләмәде. Аның чыгышларының төп темасы Русиядәге төрки халыкларның авыр тормышы, хокуксызлыгын ачып салу һәм аларның Русиядә тигез хокуклы халык булуын закон нигезендә тануның зарурлыгы турында иде. Садри Максудиның Өченче Дәүләт Думасында ясаган чыгышларыннан түбәндә китерелгән мисаллар әнә шуның ачык шаһите. Аның аерым чыгышларының темаларын санап китик:

1) Кыргыз-казак халкының җирләрен талап алу буенча патша хөкүмәте алып барган сәясәтне фаш итү, шушы сәясәт аркасында бу халыкларның юкка чыга баруын ачып салу, җир мәсьәләсе буенча гадел законнар кабул итү кирәклеге турында. Бу темага С. Максуди берничә тапкыр чыгышлар ясый;

2) Төркестан мөселманнары яши торган авылларда дәүләт тарафыннан оештырылган аракы сатуга протест белдерү;

3) Русиянең Босфор һәм Дарданелл бугазларын басып алуга корылган политикасын фаш итү, аңа протест белдерү;

4) Төрки халыкларның тел, гореф-гадәт ягыннан уртаклыгын, якынлыгын аңлату, пантюркизм дип пропагандалаучы рус шовинистларының уйдырмаларын фаш итү. Садри Максудиның бу нотыгы Думаның карагруһ, шовинист депутатларына бигрәк тә ошамый. Ораторның: «Дөньяда бөек төрек милләте бар, ул яши һәм яшәячәк, аның киләчәген бернинди көч белән дә буу мөмкин түгел»,—дигән сүзләре рус шовинистларының җеннәрен кузгата[1];

[1] Шактый зур күләмле бу чыгышның текстын табып без аны татар һәм рус телләрендә, тиешле комментарийлар белән «Идел» журналының 1991 ел, 10—11 саннарында бастырган идек.—Ә. К.

5) Төрек-Болгар сугышында Төркиягә каршы төрки халыклар катнашмаячаклар дип ясаган чыгышы;

6) Русия Мәгариф министрлыгының бары рус, христиан мәктәпләрен генә кайгыртуы, төрки халыклар мәктәпләренә бер тиен акча бирмәве генә түгел, аларны эзәрлекләүләренә каршы протест ясавы;

7) Дәүләт Думасы утырышлары бара торган Таврия бинасының түшәме чатный һәм бинага ремонт ясау кирәклеге турындагы утырышта С. Максуди да сүз алып трибунага чыга. Таврия сараеның түшәме чатный башлавы турында сүзен башлап, аннан да куркынычрак чатнау—Думага сайлау буенча чыгарылган законның аерата куркыныч чатнау, гаделсезлек икәнен, илдә «төзәтүне сорый торган иң зур, иң куркыныч чатнау» булуын аңлата, Төркестан кебек зур регионда яшәүче мөселман халыкларын сайлау хокукыннан мәхрүм итү, аларга Дәүләт Думасына юлны ябу зур хата икәнен әйтә: «Безгә менә шундый нәрсәләрне төзәтү кирәк»,—дип сүзен тәмамлый.

Садри Максудиның мәсьәләне шулай оста борып куюы, Русия халыкларының тигез хокуклыгын яклауда Таврия сараеның түшәме чатнавын да файдалана белүе либераль депутатларның алкышына күмелә, ә карагруһ-шовинист депутатларның ачуларын чыгара.

Ватандашыбыз профессор Зәки Вәлиди үзенең «Бүгенге төрек иле (Төркестан) вә аның тарихы» дигән хезмәтендә (Истанбул, 1942.—531 б.) С. Максудиның бу һәм башка күп чыгышларын «гүзәл» нотыклар дип атый, аның кайбер чыгышларына карата тәнкыйть сүзе дә әйтеп үтә.

Кемнәр ничек димәсеннәр, Өченче Дәүләт Думасында Казан мөселман депутатлары арасында Садри Максуди кебек актив катнашкан, төрки халыкларның хокукларын яклап кыю чыгышлар ясаган башка депутатлар билгеле түгел. (Бу Думада барлыгы ун мөселман депутаты булып, аларның җидесе Казан, Урал төрекләреннән, ә калган өчесе кавказлылар иде.)

Думада эшләү чорында Максудины Дума депутатлары группасы составында 1909 елда Англиягә алып барулары да юкка булмагандыр.

1911 елда ул Оренбургтагы алтын приискасы хуҗасы, «Вакыт» газетасы, «Шура» журналының нәшире Шакир Рәмиевнең кызы Камилә туташка өйләнә. (Бу никахтан аларның ике кызы туа. Өлкәне—Адилә Аида Истанбул университетының

әдәбият факультетында доцент булып эшли, француз филологиясен укыта, матбугатта актив катнаша, яхшы мөхәррир буларак таныла. Әтисе вафатыннан соң университетны калдырып Анкарага күчә, биредә Тышкы эшләр министрлыгында эшли.)

1912 елда С. Максудиның «Англиягә сәяхәт» исемле кечкенә китабы басылып чыга[1].

1913 елда С. Максуди Мәскәүдә юридик факультет программасы белән юристлыкка имтихан тапшыра, диплом ала һәм Казанга кайтып үзенең элекке танышы, күренекле адвокат Батоның ярдәмчесе булып эшли башлый[2].

АДВОКАТ БУЛЫП ЭШЛӘВЕ

1912 елгы Дүртенче Дәүләт Думасына С. Максуди инде депутат булып сайланмый. 1913 елда ул Казанга кайта һәм адвокат булып эшли башлый. Бу елларда ул җәмәгать эшләреннән дә читләшә, мин аның вакытлы матбугатта мәкаләләр белән катнашуын да хәтерләмим[3]. Күрәсең, анда бу елларда андый теләк көчле булмаган. Абыйсы чыгара торган «Йолдыз» газетасында дүрт ел эшләү чорында (1913—1917) С. Максуди бу газетага бары бер генә мәкалә язды. Ул 1914 елның сентябрендә басылган, Исмәгыйль бәй Гаспралының вафаты уңаеннан «Бөек гамәлләр остазы» исеме белән чыккан некролог[4].

---

[1] Г. Баттал бу басманы күрмәгән булса кирәк. Ул «кечкенә» китапның күләме унике табак чамасы, гаять информацион, әһәмиятле тарихи хезмәт. Аннан бу басма 1912 елда түгел, ә 1914 елда Казанда, «Өмет» электро-типографиясендә басыла, ә аңа хәтле «Йолдыз» газетасы битләрендә дөнья күргән була.—Ә. К.

[2] «Җөмһүрият» газетасының 1957 ел, 1 март санында Адилә Аида «Әтием Садри Максуди» дигән мәкаләсендә әтисенең 1906 елда Париждан кайткач ук юридик фәннәр буенча имтихан тапшырып юрист дипломы алуы, ләкин Думага сайланулар мәшәкате белән адвокат булып эшли алмый калуын яза. Бу дөреслеккә туры килми. Ул юридик факультет программасы буенча имтиханнарны 1913 елда тапшыра. Бу турыда аның 1913 елда Казан адвокатлар коллегиясенә язган хатында да әйтелгән, бу хакта ул заманда чыккан вакытлы матбугатта да хәбәрләр бар.—Г. Б.

[3] Җанбәк псевдонимы астында С. Максудиның 1911 елда Истанбулда «Төрек йорты» журналының 1, 2 саннарында басылган «Бөек милли гамәлләр» исемле мәкаләсе билгеле.—Г. Б.

[4] Бу мәкаләдән зур гына өзек кырымлы галим һәм сәяси эшлекле Җафар Сәйетәхмәднең 1934 елда басылган «Гаспралы Исмәгыйль бәй» исемле китабында да китерелгән.—Г. Б.

1917 ЕЛ РЕВОЛЮЦИЯСЕ

«ТӨРКЕСТАН КОМИТЕТЫ»НДА

Белгәнебезчә, 1917 ел февраль революциясеннән соң кадетлар партиясе (конституцион демократия) лидеры князь Георгий Львов җитәкчелеге астында Дума урынына Русиядә беренче революцион хөкүмәт оештырыла. Күренекле тарихчы, Думадагы кадетларның лидеры Павел Милюков бу яңа хөкүмәттә чит ил эшләре министры итеп билгеләнә. Садри Максуди кадетлар партиясенең лидерлары белән Икенче һәм Өченче Думада депутат булган вакытта таныш була, хәтта аларның дуслар булуы да мөмкин[1].

С. Максуди Дүртенче Дума депутаты булмаса да, кадетлар партиясенең әгъзасы буларак аның лидерлары белән бу чорда да тыгыз элемтәдә яши. Революция көннәрендә кадетлар партиясенең съездында катнашу өчен аның Петроградка килүе шуны сөйли. Съездның бер утырышында ул Русия мөселманнары кадетлар партиясен яклаячак дип белдерә. Бу вакытта хөкүмәт башына килгән кадетлар партиясе лидерлары, аның белән сөйләшеп, хөкүмәт каршында төзелгән «Төркестан комитеты»на С. Максудины бу комитет әгъзасы итеп тә алалар. Ә бу комитетка Төркестан белән эш итү бурычы йөкләнгән була.

Биредә шуны да искә алып үтәргә кирәк. «Мөселман иттифакы» партиясен оештыручылар 1905 елгы революция көннәрендә сул партияләргә якын, аның программасы да кадетлар программасына охшаш, социалистик республика төзү программасын хәтерләтә иде. Бу сәяси «Мөселман иттифакы» партиясен оештыручылар арасында түбәндәге зыялыларны са-

[1] «Англиягә сәяхәт» китабында С. Максудиның Англиягә сәяхәт вакытында П. Милюков белән дустанә аралашуы, якынлыгы турында сөйләүче гамәлләр шактый күп искә алынган.—Ә. К.

нап үтү күп нәрсә турында сөйли. Алар: Кавказлы Гали Мәрдән бәй Тупчыбашов, кырымлы Исмәгыйль бәй Гаспралы, себерле Габдрәшид Ибраһим казый, казанлылардан адвокат Сәедгәрәй Алкин, мөхәррир Йосыф Акчура һәм башкалар[1].

1917 елгы революциягә хәтле «Иттифак» партиясе инде эшләүдән туктаган була. Аның эшен Думадагы «Мөселман фракциясе» дәвам итә. Бу фракциянең үзәк шурасының әгъзаларыннан берсе Садри Максуди була. Икенче һәм Өченче Думада «Мөселман фракциясе» Русия парламентына мөселман депутатлары сайлауга юллар ачу өчен дә тырыша. Фракциянең шул эшне башкару өчен махсус бюросы да оештырыла.

Яңа хөкүмәттәге кадетлар лидерлары тырышлыгы белән «Төркестан комитеты»на кертелгән Садри Максудиның бу уңай белән мөселман сәяси оешмаларыннан ризалык алуы билгеле түгел.

«Төркестан комитеты» тугыз кешедән төзелә, аларның бишесе рус кешеләре, а калган дүртесе—мөселманнар. Аның рәисе кадетлар партиясенең күренекле лидерларыннан Щепкин исемле рус кешесе иде. Комитет әгъзаларыннан мөселманнардан казакъ вәкилләре Алихан Букейханоглы[2], Мөхәм-

---

[1] Садри Максуди үзенең миңа язган хатында «Иттифак» партиясенә 1907 елның августында керүен яза. Бу чорда Русия мөселманнары арасындагы сәяси хәрәкәтне чагылдырган «Ислахәт әсаслары» (Петроград, 1915) китабында Муса Ярулла Биги бу турыда искә алмаган.—*Г. Б.*

[2] А. Букейханоглы Тургай вилаятенең комиссары итеп тә билгеләнгән була, ләкин ул Ташкентта эшли башлаган «Төркестан комитеты»на килә алмый, аның эшчәнлегендә дә катнашмый. Ә Мөхәммәтҗан инженер була. Аның этнография һәм тарих буенча дөнья күргән хезмәтләре дә бар (Г. Баттал искәрмәсе).

Ә. Кәримуллин искәрмәсе: 60 еллар башында Казан университетында математика профессоры Гагаев җитәкчелегендә физика-математика буенча кандидатлык диссертациясе язу буенча аспирантурада Казакъстаннан килгән, минем якын дустым Имбергән Омаров укый иде. (Соңыннан ул Караганда политехник институтында математика укытты, профессор булды.)

Ул мине бер казак сәяси эшлеклесе булган кеше белән таныштырам дип шәһәрнең Ленин районына алып барды. Ул кеше бер бүлмәле фатирда яши иде. Бу әнә шул Галихан ага булып чыкты. Ул озак еллар Сталин гулагларында интеккән, шулай да исән калган, хәзер Казанда яшәп ята икән. Аңа Казакъстанга кайтырга рөхсәт бирелмәгән. Бу очрашуда мин аның Алашурда, казакъ халкының милли азатлык хәрәкәте белән бәйле булуын, шуның өчен кулга алынуын аңладым. Ул Казанда вакытта татар социал-демократлары белән дә бәйле булган. Хөсәен Ямашев вафат булгач, аның хатыны Хәдичә ханымга өйләнеп, тормыш корып җибәргән. Хәтерем ялгышмаса, ул үз вакытында Казанга ветеринария институтына укырга килгән булган, шунда татар зыялылары белән аралашып киткән.

мәтҗан Тынышбайоглы, казанлылардан ике кеше. Берсе Төркестанда генерал-губернатор Куропаткин кул астында революциягә хәтле эшләгән генераллардан Габделгазиз Дәүләтшин. Бу кеше сәясәттән ерак торган, үзенә йөкләнгән вазыйфаларны төгәл, вакытында үтәп килүе белән танылган служака була. Ә икенчесе—Садри Максуди.

Төркестанлы казакъ сәясәтчеләреннән Мостафа Чокайоглы үзенең бер китабында «Русия Дәүләт Думасындагы мөселман депутатлары арасында иң тырышы, эшлеклесе, һичшиксез, Садри Максуди иде», дип күрсәтеп үтә. «Рус либерал-демократлар партиясе әгъзасы булуы сәбәпле ул кайбер мәсьәләләрдә чигенүләргә барырга мәҗбүр булды. Менә шуның аркасында Төркестан мәсьәләләрендә тулысынча эзлекле позиция үткәрә алмагандыр». Бу турыда без алда киңрәк тукталырбыз[1].

Садри Максудиның бу Комитетта эшчәнлегенә күчкәнче ул замандагы сәяси хәлне ачыклап китәргә кирәк. Бу безгә ул Комитет әгъзаларының бу ситуациядә үзләрен ничек тотуларын аңларга да ярдәм итәр.

«Төркестан комитеты»ның социаль-иҗтимагый программасы һәм хөкүмәт тарафыннан билгеләнгән эш положениеләрен тормышка ашыру, һичшиксез, Русия революциясенең барышы һәм биредәге ситуациягә бәйле була. Бу чорда «Икевластьлык» хөкем сөрә. Берсе—Думаның вакытлы комитеты тарафыннан игълан ителгән революцион вакытлы хөкүмәт, икенчесе—эшче һәм солдат советлары. Боларның соңгысы коралга, көчкә таянып эш итә, шуңа күрә көннән-көн көчәя, торган саен суллаша бара. Мәркәздәге бу икевластьлык регионнарга да килеп җитә, шул исәптән, Төркестан краена да. Комитетка үзе алдына куелган бурычларны уңышлы үтәү өчен, бер яктан, җирле мөселман оешмалары, ә икенче яктан, биредәге эшче һәм солдат комитетлары белән килешеп эшләү кирәклеге туа. Башта биредә мөселман оешмалары эшчәнлеге өстенлек ала, шуңа күрә «Төркестан комитеты» алар белән күпмедер хисаплашырга мәҗбүр була. Ләкин мөселманнарның мил-

---

[1] «1917 нче ел хатирә парчалары».—Т. 1.—Париж-Берлин.—1937.—Б. 41. Чокайоглының икенче, 1947 елда Истанбулда басылган «Рус ихтилалыннан хатирәләрем» китабы белән дә таныштым. Ул анда, кадетлар партиясе «Рус милли партиясе» генә түгел, башка милләтләрнең мәнфәгатьләрен дә кайгыртучы партия иде, дип яза. Бу партиягә төрекләрдән Али Мәрдән Тупчыбаш, Галихан Букейханоглы кебек күренекле зыялылар да керүен шуның белән бәйли. 1917 елдан соң, ситуация үзгәрү белән, бу партиянең дә сәясәте үзгәрде, ди.—*Г. Б.*

ли оешмалары әле йомшак, җитлеккән кадрлар аз булуы аркасында алар үзләренә уңай булган хәлләрдән яхшырак файдалана белмиләр, шуңа күрә үзләренең максатларына ирешә алмыйлар[1]. Комитет милли оешмалар һәм аңа мөрәҗәгать иткән зыялыларның фикер, тәкъдимнәренә күз йомып килә, җирле халык арасында авторитет казана алмый. Эшче һәм солдат комитетлары белән дә бергәләшеп эшләүнең перспективасызлыгын аңлагач, Комитет әгъзалары Преображенский, казанлы Г. Дәүләтшин һәм адвокат Садри Максуди да июнь аенда Ташкенттан китәләр.

Бу уңай белән М. Чокайоглы «Елпатневский һәм Липовский кебек М. Садри да Ташкентта кала алыр иде. Аның биредән китмәве безнең өчен бик файдалы булыр иде» дип яза[2]. Чокайоглы язуы буенча, бу Комитет бары ай ярым тирәсе азмы-күпме тыныч шартларда эшли алды, Ташкентка килеп, эшли башлауга биредәге эшче һәм солдат комитетлары белән Щепкин арасында каршылыклар, аңлашылмаучанлыклар килеп чыга. Урында совет власте көчәя барган саен Вакытлы хөкүмәт органы булган бу Комитетның власте, көче юкка чыга башлады. Совет власте урнашкач бу Комитет уенчык органга әйләнде. С. Максуди Щепкин, Дәүләтшиннардан аерылып Ташкентта калган булса да, аның зур эшләр майтаруга көче җитмәс иде. Биредә калган булса яңа ситуациядә берни эшли алмас иде. Үзенең буйсынмас табигате, мөселман халыкларының тигез хокуклыгы идеалларына туры булган С. Максуди биредәге революцион элементлар белән көрәшү юлына басар идеме икән...

КОМИТЕТТАН КИТКӘЧ

«Мөселман иттифакы» партиясен оештыручылар (1905) башлангыч чорда сул канатта торган кадетлар партиясе белән бергә эшли алсалар да, 1917 елдан соң ситуация нык үзгәрә. Мәркәздә эшче һәм солдат депутатлары Думадагы «урта» социалист саналган Керенский, Скоболев, грузин Чхеидзе кебек депутатларны депутатлыктан куу юлына басалар. Алар, таләп артыннан таләп куеп, үзләренә ошамаган министрларны эшләреннән алдыралар, үз кандидатларын көчләп тагалар, кыскасы, бернәрсә белән дә исәпләшми башлыйлар.

---

[1] М. Чокайоглы. Күрсәтелгән әсәр. Б. 36—37.—Г. Б.
[2] Шул ук.—Б. 42.—Г. Б.

Тора-бара кадетлар партиясе лидерлары да власть башыннан куела, партиянең дә эшчәнлеге тукталып кала. Бу партиягә ышанган С. Максуди һәм башкаларга да бу авыр тәэсир итми калмаган, әлбәттә.

Кадетлар партиясенең съездында төрек халкының бөеклеге һәм аны беркем җиңә алмаячагы турындагы чыгышы Садри Максудига кыйбатка төшә. Аның бу чыгышына каршы протестлар оештырыла, матбугатта аңа каршы мәкаләләр басылып тора һәм нәтиҗәдә ул Учредительное Собраниегә делегат булып үтә алмый кала. Моның сәбәпләрен кайберәүләр С. Максудиның корырак табигатьле, һавалырак кеше, аның холкына бәйләп аңлатырга тырыштылар.

1917 ел революциясе 1905 елгысы кебек башланса да, ул икенче юл белән китте, шуның аркасында күп кенә сәясәтчеләр дә аны дөрес аңлап житкермәделәр. Зәки Вәлиди һәм тәҗрибәле Садри Максуди да бу революциянең нинди юл белән барачагын дөрес күзаллый алмадылар, шактый ялгыштылар. «Төркестан комитеты»нда эш белән мәшгуль булган Садри Максуди 1917 елның маенда Мәскәүдә үткәрелгән Беренче Бөтенрусия мөселманнары съездына катнаша алмады. Бу съездда ул кемнәрне—«федералист» яки «унитаристларны» яклап чыккан булыр иде, бу билгесез калды. Садри Максуди съездда катнашмаса да, съезд аны Мөселман мәркәз шурасына әгъза итеп сайлады.

МИЛЛИ-МӘДӘНИ МӨХТӘРИЯТ

Мәскәүдә үткәрелгән бу корылтай Русияне федерализм тәртибендә үзгәртеп кору белән бергә, үз берлекләре, республикалары булмаган халыклар өчен «Милли-мәдәни мөхтәрият» төзү турында карар кабул итте. Мондый мөхтәриятның нәрсә икәнен тирәнтен ачыклау өчен Садри Максуди Австрия социал-демократлары Отто Бауэр һәм П. Шпрингерның милли мәсьәләләргә багышланган хезмәтләрен җентекләп өйрәнергә тотына[1].

[1] Беренчесенең әсәре «Милли мәсьәлә вә социал-демократия», ә икенчесенең хезмәте «Миллият проблемалары» дигән исемнәр астында билгеле. С. Максуди үзенең соңгы, 1955 елда Истанбулда чыккан «Миллият тойгысының социологик әсаслары» дигән китабында бу әсәрләрнең рус теленә дә тәрҗемә ителгәнлеге һәм шул басмалар буенча өйрәнүен искә алып үтә.— Г. Б.

Бу авторлар милли мәсьәләләрне, шул исәптән сан ягыннан азчылыкны тәшкил иткән халыкларның хокукларын киң планда өйрәнеп, бер дәүләт эчендә яшәүче вак милләтләргә милли-мәдәни мөхтәрият оештыру гаҗизлеген исбатлап чыгалар. Азчылык тәшкил иткән милләтләрнең хокуклары системасын билгелиләр.

Хушына туры килгән бу хезмәтләргә таянып С. Максуди Русия һәм Себердә яшәүче төрек-татарлар өчен милли-мәдәни мөхтәрият оештыру проектын әзерләргә керешә һәм 1917 елның июлендә Казанда үткәрелгән Икенче Бөтенрусия мөселманнары корылтаена алып та килә.

Әзербәйҗанлылар, Төньяк һәм Көньяк Төркестан төрекләре, хәтта башкорт төрекләре бу заманда үзләре яши торган җирләрдә «туфраклы мөхтәрият» мәсьәләләрен көн тәртибенә кую белән мәшгуль булу сәбәпле бу корылтайга үзләренең вәкилләрен җибәрмәгәннәр. Шунлыктан бу форум Бөтенрусия мөселманнары корылтае дип түгел, ә «Эчке Русия һәм Көнбатыш Себер мөселманнары корылтае» дигән исем ала. Корылтайда С. Максуди төзегән «Милли-мәдәни мөхтәрияты» укыла, тикшерелә һәм кабул да ителә. Бу вакытта Казанда голәма-дин әһелләре корылтае һәм мөселман хәрбиләре корылтайлары да үткәрелә. Шушы өч корылтай вәкилләре катнашында 1917 елның 22 июлендә Казанда, зур тантана белән «Эчке Русия һәм Көнбатыш Себер» төрек-татарларының «Милли-мәдәни мөхтәрияты» игълан ителә. Бу мөхтәрият нигезләрен, корылтай карарларын тормышка ашыру өчен корылтайда «Мөхтәрият һәйәте» төзелә, аның рәисе итеп С. Максуди сайлана. Һәйәт эше урыны итеп Уфаны сайлый һәм ул 1917 елның 30 ноябрендә «Эчке Русия һәм Себер төрек-татарларының Милли мәҗлесе»н чакыра. Милли мәҗлес һәм бу Мәҗлес тарафыннан оештырылган «өч нәзарлы» Милли идарәнең рәисе итеп тә Садри Максуди сайлана. Бу Милли идарә 1918 елның 19 январенда оештырыла, ә инде 1918 елның 25 апрелендә ул Диния нәзарәтенең бүлеге булып кына «кала». Бу Мәскәү приказы, совет власте органнары тарафыннан безнең милли-мәдәни мөхтәриятны юкка чыгаруы иде. С. Максуди проектына нигезләнеп төзелгән безнең милли-мәдәни мөхтәрият, аның рәислеге астында ук эшләгән Милли идарәнең дә гомерен советлар менә шулай

бик тиз кистеләр, ул нибары өч ай һәм 6 көн генә эшләп калды[1].

Милли идарә таркатылды. Хәлләр авырая, көннән-көн начарлана бара. Милли идарә әгъзаларын эзәрлекләү, кулга алу башланганчы ук, күңеленнән сизеп булса кирәк, аның рәисе Уфаны ташлап, 1918 елның маенда аннан чыгып китә. Аны Казанга китте дип уйлыйлар. Ул Уфадан туры Мәскәүгә юл тота, анда Гаяз Исхакый белән мөселманнарның Милли идарәсен ябуга протест белән Совет хөкүмәтенең Югары органнарына шикаять җиткерә.

Милли мәҗлес таркалган бу көннәрдә Русиядә пленда булган чехословак солдатлары кулларына корал тотып баш күтәрделәр, рус акгвардеецлары белән бергәләп, урыннардагы совет органнарын таркатып үз илләренә кайту өчен Шәрыкка таба кузгалдылар. Бу катлаулы көннәрдә Садри Максуди һәм Гаяз Исхакый кеше күзеннән ераграк булырга тырышалар, алар Мәскәүдән икәүләп Түбән Новгород вилаятенең мөселман төрекләр яши торган авылларына юл тоталар. Биредә аларның юллары аерыла. Төрмәләрдә, сөргеннәрдә «чыныккан», күпне күргән Гаяз Исхакый кыяфәтен үзгәртеп, крестьян киеме киеп фронт линиясе узып Казанга килә. Бу вакытта Казан чехословаклар кулында була. Аннан, чехлар восстаниесе үзәге булган Самарага юл тота.

АУРУПАГА

Садри Максуди бу көннәрдә авылда озак калуның куркыныч икәнен белгәнгә күрә, ул да яңадан юлга чыга. Ул, Г. Исхакый кебек, Казанга юнәлми. Мыек-сакал үстереп җибәрә, өс-башын алыштырып «крестьян»гә әверелә һәм аны белгән һәм хөрмәт иткән кешеләр ярдәмендә Петроградка барып чыга. Бу вакытта анда күренекле галим, сәясәтче Муса

[1] Без башта бу «Милли-мәдәни мөхтәрият» проектын Г. Исхакый һәм аның аркадашы Әхмәт Цаликатти (Г. Исхакый аны «Салихов» дип йөртә) әзерләгән дип уйладык. Һич югында ул аларның яклавын тапкан дип белдек. Миңа озак еллардан соң Истанбул янындагы Мәҗидия дигән авылда профессор В. Турханның җәйге бакчасында С. Максуди белән сөйләшеп утырырга туры килде. Сүз уңаеннан сүз чыгып бу проект турында да сөйләшә башладык. Ул миңа бу ике сәясәтченең аның проектына катгый рәвештә каршы чыгуларын күп фактлар белән раслады. Корылтай бу проектны тулысынча диярлек бердәм яклый башлагач, бу ике зат та аңа кушылганнар.—*Г. Б.*

Ярулла Бигиев яши. Аның ярдәме белән С. Максуди 1918 елның көзендә Финляндиягә юл ала.

Менә шушы вакыттан С. Максудиның Русиядәге эшчәнлеге тәмамлана, сәяси эмиграция чоры башлана.

ТАРИХ ЯЛГЫШМАСЫН

Тарихта хата китмәсен өчен бер мәсьәләне ачыклау кирәк дип саныйм. С. Максудиның хөрмәтле вә акыллы кызы Адилә Аида «Җөмһүрият» газетасының 1957 ел, 1 мартында басылган «Әтием Садри Максуди» дигән мәкаләсендә «Милли-мәдәни мөхтәрият игълан ителгәч» дигән сүзләрдән бераз астарак төрек-татарларның «Автономияле дәүләтенең Милли идарәсе бар иде, бу *дәүләтнең*[1] башбаканы итеп Садри Максуди сайланган иде» дип яза. Анда тагын шундый характердагы «дәүләт» сүзе кулланыла: «Большевиклар бу төрек *дәүләтен* җимерделәр» дип өсти. Икенче төрле әйткәндә, Милли-мәдәни мөхтәриятне *дәүләт* мәгънәсе белән тиңли.

Билгеле булганча, дәүләтнең чикләр белән билгеләнгән территориясе, ул территориядә яши торган халкы була. Бер шагыйрьнең сүзе белән әйткәндә, дәүләт үлгәннәрнең дә, исәннәрнең дә *ватаны* ул.

«Милли-мәдәни мөхтәрият» ул «туфраклы мөхтәрият» түгел. Беренче территорияләре билгеләнмәгән, төрле регионнарда аралашып яши торган төрек халыкларының мәдәниятын, гореф-гадәтләрен, мәгарифен кайгыртучы бер идарәне күздә тота. Мәскәүдә үткәрелгән мөселман корылтае да аны шушы мәгънәдәге идарә дип кабул итте. Димәк, С. Максуди да Милли-мәдәни мөхтәриятне *дәүләт* дип бәяләмәде, үзен дә булмаган *дәүләтнең* башбаканы дип йөртмәде, кыскасы, күрсәтелгән мөхтәрият *дәүләт* тәшкил итмәде. С. Максудиның максаты «Эчке Русия һәм Себер мөселманнарының» милли, дини, мәдәни мәнфәгатьләрен яклаучы сәяси идарә төзү иде. Ә аның аркадашы, чит илләрдәге эшчәнлеге чорында, «Идел-Урал *дәүләте»*н төзү идеясен күтәреп чыкты. Максуди бу идея белән артык кызыксынмады, эмиграциягә киткәч үзенең «Милли-мәдәни мөхтәрият» идеясе белән дә янып йөрмәде.

Соңгы вакытларда С. Максудиның «Милли-мәдәни мөхтәрияте»н Г. Исхакыйның «Идел-Урал дәүләте» идеясе

---

[1] Бу бүлектәге курсивлар безнеке.—*Ә. К.*

белән бер үк нәрсә дип бәяләү күренә башлады. Бу фикер чит илләрдә дөнья күргән аерым хезмәтләрдә дә очраштыргалый. Адилә Аидага хәтле бу карашны алга сөргән бер мәкалә Мюнхенда чыга торган «Dergi» мәҗмугасының алтынчы санында да күренгән иде. Бу авторга аның карашының дөреслеккә туры килмәвен күрсәтеп 1956 елның 30 ноябрендә тәфсилләп хат язган идем. Дөреслеккә туры килми торган бу караш 1957 елның март аенда чыккан (№ 266) «Төрек йорды» журналында да алга сөрелә. Бу мәкаләнең авторы доктор Фәтхи Әрдән «Садри Максуди яңа торгызылган *Казан дәүләтенең* рәисе иде», дип яза. Анда С. Максуди биографиясенә караган башка аерым төгәлсезлекләр дә очрый. Янәсе С. Максуди мәдрәсәдән соң укытучылар әзерли торган *югары* уку йортында укый, Төркия мәҗлесенә Истанбулдан сайланды...

Менә мондый күренешләр газета, журналларда басылган мәкаләләрдә очраштыргалый. Җәмәгатьчелек фикерен бутауга китерә торган мондый төгәлсезлекләр фактларның асылына тиешле игътибар итеп җиткермәүдән килә, ә моның тарихны бозып күрсәтүгә юл ачуы бар.

С. МАКСУДИ АУРУПАДА

ФИНЛЯНДИЯДӘ

Финляндиядә яшәүче мөселман милләттәшләребез С. Максудины, сәясәт өлкәсендә актив эшләгән бу зыялыны, үз кардәшләре кебек итеп, чын күңелдән яратып каршы алдылар, аның хәлен җиңеләйтү өчен тырыштылар, матди яктан да ярдәм иттеләр, Финляндиянең күренекле кешеләре белән дә таныштырдылар.

Дума трибунасыннан Русия кул астында булган Финляндиянең автономия хокукларын, Финляндиянең Конституциясенә бу илгә мөстәкыйльлек өчен үзгәрешләр кертүне яклап чыгучы мөселман депутаты шушы С. Максуди булуын белгәч, Финляндиянең дәүләт эшлеклеләре һәм зыялылары аңа зур хөрмәтләр күрсәтәләр, үзләренең дусты, кадерле кунагы итеп кабул итәләр.

Милләттәшләребез С. Максуди шәрәфенә зур банкет та оештыралар, анда фин халкының күренекле кешеләре дә катнаша. Банкетта С. Максуди француз телендә нотык белән чыга һәм бу чыгышында ул үзенең сәяси эшчәнлеге турында да сөйли.

БЕРАЗ ВАКЫТ ПАРИЖДА

С. Максуди үзенең миңа язган бер хатында Финляндиядә 9—10 ай чамасы калуын һәм 1919 елның маенда Парижда үткәрелә торган Солых конференциясенә һәм анда «Эчке Русия һәм Себер төрекләре»[1] хокукларын яклап доклад ясарга баруын язган иде.

---

[1] Г. Баттал үзенең бу хезмәтендә «Эчке Русия һәм Себер» дигән терминнан соң я «төрекләре», я «мөселманнары», я «төрек-татарлары» дип күрсәтә. Без, автор ничек язса, шулай күрсәтәбез.—*Ә. К.*

Париж аның өчен ят шәһәр түгел иде. Ул анда элек дүрт ел яшәгән, күп кешеләр белән танышкан, дуслашкан була. Шуның өстенә Парижда аның Русиядән килеп төшкән танышлары да шактый була. Алар—революциядән соң Русияне ташлап киткән Дума депутатлары, дуслары, фикердәшләре, танышлары. Бу эмигрантларның күбесе биредә Совет властена каршы пропаганда алып бару, матбагачылык-нәшрият эшләре белән шөгыльләнәләр икән.

БЕР «СОЛЫХ КОМИССИЯСЕ»

С. Максуди менә шулай итеп икенче тапкыр Парижга килеп чыга. 1918 елда, Русиядән качып китеп чит илләрдә яши башлаган бу чорда, Совет властен урнаштыру башлану белән, илдә хәрби восстаниеләр үсә, бу Русиядә гражданнар сугышын китереп чыгара. Русиянең Совет власте әле үтеп кереп җитмәгән регионнарында төрле-төрле «дәүләтләр» игълан ителеп тора. Илдә мәхшәр, ачлык, талау-җимерү, террор...

Бу шартларда безнең «Милли-мәдәни мөхтәрият» тарафдарлары да тик ятмый, уяна, берләшә, эшкә керешә. 1918 елның 21 сентябрендә үзенең Мәҗлесен ачып җибәрә. Бу мәҗлескә төрек-мөселманнар яши торган регионнардан вәкилләр җибәреләә. Уфага фронт якынлаша башлагач, Мәҗлес Кызылъяр (Петропавел) шәһәренә күчеп китә. «Эчке Русия һәм Себер төрек-татар»лары Милли идарәсенә сайланып куелган әгъзаларның берничәсе аның эшен дәвам итә. Элекке Милли идарәнең рәисе С. Максуди «яңа» Милли идарәдә катнаша алмаса да, аның урынбасары адвокат Бениамин Әхмәтов һәм тагын берничә кеше бу идарә эшен дәвам итәләр. Бу Идарәне эмиграциядәге Милли идарә дип атарга була.

Шулай итеп, 1919 елның язында Милли идарәнең Урал, Себер якларына килеп чыккан вәкилләре «Кече Милли мәҗлес» оештырып эш башлап җибәрә һәм шушы Мәҗлес Парижда үткәреләчәк Солых конференциясенә вәкилләр дә сайлый. Аларның берсе Фуат Туктаров, ә икенчесе Гаяз Исхакый була. Бу Конференциядә Милли Идарә рәисе С. Максудиның да катнашуын зарури күргән Мәҗлес боларга, Аурупага барып чыккач аны табып, Мәҗлес исеменнән аның аның да вәкил булып сайлануы турында мандат тапшыруны, өчәүләп шушы Конференциядә эшләргә полномочиеләр бирә. Бу өч кеше Парижда очрашып «Тулы Солых комиссиясе» дә оештыралар.

Кызылъярда Мәҗлес тарафыннан сайланган бу ике вәкилнең Парижга юлы җиңел булмый. Ерак Шәрыкка авырлыклар белән барып җиткән бу ике кеше, восстание күтәреп үз илләренә кайту өчен юл ачкан әсир чехословаклар белән бергә, Аурупага юнәләләр һәм океаннар аша узып Прагага килеп җитәләр. Моннан Франциягә китәләр һәм Парижда С. Максудины эзләп табып, инде өстә искә алынган «Тулы Солых комиссиясе» оештыралар. Бу 1920 елның азакки көннәрендә була. Бу вакытта Версальдәге Солых төзү конференциясе инде үзенең эшен тәмамлаган, Себер һәм океаннар гизеп Парижга килгән Ф. Туктаров, Г. Исхакый инде соңга калган булып чыгалар. С. Максуди Версаль Солых конференциясенә Русиянең төрек-мөселманнарының хокукларын яклау буенча меморандум белән мөрәҗәгать иткән була. Г. Исхакый белән Ф. Туктаров бу меморандумга кул куярга соңга калган булалар һәм аның эчтәлеге белән дә таныша алмый калалар. Шуны да искә алып үтү кирәктер: Беренче бөтендөнья сугышыннан соң үткәрелгән бернинди конференциядә дә Русия мәсьәләсе каралмаган. С. Максудиның бу меморандумының кайсы конференциягә бирүе дә ачыкланмаган. Меморандумның эчтәлеге дә конкрет ачык түгел. Парижда үткәрелгән бу конференциянең эшчәнлеге турында да бернинди хисап басылмаган. Г. Исхакыйның хезмәтләрендә дә бу турыда бер сүз әйтелми.

Г. Исхакый белән Ф. Туктаровның Ерак Шәрыкта тоткарланулары һәм биредә яшәүче якташларыбызның аларга ярдәме, конференциягә соңга калуларының тарихы турында Харбиндагы күренекле сәүдәгәр Әмруллаһ Агиоглының[1] Гаяз Исхакыйга язган хатында шактый кызык мәгълүматлар бар:

«Сез язган мәкаләдә (кайда, ни исем белән басылуы күрсәтелмәгән) Харбиндагы мөселман мәхәлләсен Сез кимсеткәнсез, җәмгыятьнең милләтебез язмышы өчен башкарган хезмәтләрен күрмәмешкә тырышкансыз, мәхәллә һәйәте тарафыннан «Солых конференциясе»нә барыр өчен ярдәмен дә искә алмыйсыз. Харбинның мөселман мәхәлләсенең һәйәте «Солых конференциясе»нә баручы вәкилләргә зур кунакчыллык күрсәтеннән тыш, аларга алтын белән 3000 иен (япон валютасы) да бирде. Күрсәтелгән һәйәт моннан тыш, Сезгә

[1] Әмруллаһ Аги турында тулырак мәгълүматны безнең «Ватаным Татарстан» газетасында (1992, 23 октябрь) басылган «Әмруллаһ Аги язмасы» дигән мәкаләдән карагыз.—*Ә. К.*

Владивостокта тугыз кадак—фунт алтын да биргән иде. Соңыннан сезгә, Аурупага янә алтын белән 970 иен валюта да җибәрдек бит.

Сез бу ярдәмнәр һәм аны кемнәр бирүе турында бер җирдә дә искә алмыйсыз. Шуны да искә төшерү кирәктер, Сез Владивостоктан чыкканда «Солых конференциясе» инде ябылган иде. Икенче төрле әйткәндә, Сез вәкаләтле вәкил булудан туктаган идегез. Бу турыда да бер сүз дә әйтмисез». (Бу ачык хат 1935 елның 24 гыйнварендә язылган.)

С. Максудиның искә алынган меморандумы «Солых конференциясе»нә тапшырылуы турында Парижда басылган «Les penseurs de l'Islam» дигән китапта искә алына[1]. Бу мәкаләнең авторы С. Максудины белгән француз кешесе аның бу чорда тарихи һәм тел гыйлеме проблемалары буенча эшләвен дә яза.

1922 елның язында С. Максуди үзенең гаиләсе белән Парижга күчеп килә. Аның гаиләсенең Аурупага барып чыгуының үз тарихы бар. С. Максудиның дуслары аның гаиләсен яшерен рәвештә Финляндиягә алып чыгуга ирешәләр. Бирердә аларны милләттәшләребез каршы ала, урнаштыра, матди яктан ярдәм итә. Аларның Финляндиягә килүен ишеткәч С. Максуди Финляндиягә ашыга, бераздан алар белән юлга чыга һәм Германиядә туктап кала. Сәбәбе: бу вакытта тормышның Германиядә, Франция белән чагыштырганда, матди яктан җиңелрәк булуында.

С. Максудиның кызы, алда искә алынган, «Җөмһүрият» газетасында басылган мәкаләсендә «Без озак вакытлар күченеп йөрүләрдән соң Берлинга килеп төштек. Биредә әтием фәнни тикшеренүләргә кереп китте, иртәдән кичкә кадәр китапханәләрдә утырды. Шушы вакытта ул Төркия тарихы буенча китап та язган икән», дип яза.

СӘЯСӘТТӘН ЧИТТӘ

Русиядә тулысынча сәясәт дөньясында гизгән С. Максуди Аурупага барып чыккач, башта бераз «Милли-мәдәни мөхтәрият» кебек сәяси эшләр белән шөгыльләнсә дә, соңыннан ул гомерен нигездә фәнни эшкә багышлый. Аның Ауру-

[1] Il présente a la conférence de la paix un mémorandum sur les revendications des musulmans de la Russia de l'Europe. Il écrit chez nous, il s'occuper de travaux historiques et philologiques.—*Г. Б.*

пага килгәч язган беренче фәнни хезмәтләре «Le Tempes» газетасы, «Journal Asiatique» журналы битләрендә басылып чыга. Күрсәтелгән журналдагы мәкаләсендә ул Кытайда Һью-һе дип билгеле булган кабиләләрнең Орхон язмаларында искә алына торган төрек Токуз-Огуз кабиләләре белән бер үк кабиләләр булуын күтәреп чыга[1].

Авторның бу фикеренә каршы профессор Фуад Көпреле тәнкыйть белән чыга[2]. Үз чиратында С. Максуди «Turk yurdu» журналында бу тәнкыйтькә тәнкыйть белән җавап бирә.

Адилә Аиданың искә алынган мәкаләсендә «Төрек тарихы турында» исеме белән Төркиядә чыккан бер китапның авторы да аның әтисе булырга кирәк. Аның Аурупада язган хезмәте «Төрекләр тарихы»мы яки икенче башка китапмы, бу турыда ачыклык юк әле.

Югарыда искә алынган француз галименең язуына караганда, Аурупада ул төрек халкының үткәне һәм аның тарихта тоткан ролен өйрәнү өстендә эшләгән[3]. Бу хезмәтнең басылуы турында да бездә мәгълүматлар юк. Бәлки, ул хезмәт француз телендә басылгандыр? Бәлки, бу китап турында белүчеләр бардыр?

Һәрхәлдә аның Аурупада язылган, Төркиягә алып кайткан «Төрек теле өчен» дигән китабы булуын беләбез. Аның бу әсәре Гази Мостафа Кемалга—Ататөреккә дә ошаган һәм 1930 (!—*Ә. К.*) елда «Төрек Очагы»ның гыйльми вә сәнагать һәйәте нәшриятында басылып та чыга[4]. Аурупага барып чыккач, үзенең «Милли-мәдәни мөхтәрият» Милли идарәсе рәисе икәнен онытмаган хәлдә, төрек халыклары тарихы, тел мәсьәләләрен өйрәнүгә керешеп китә. Берлинда, Г. Исхакый белән бергә, Русия төрек-татарларының тарихын өйрәнү буенча фәнни һәйәт төзү проекты өстендә дә эшли. Аның максаты: төрек-татар халкының тарихын торгызу, аның үткәне

---

[1] Аның бу мәкаләсе соныннан төрек теленә тәрҗемә ителеп «Төрек йорды» журналының алтынчы санында да басылды.—*Г. Б.*

[2] Бу тәнкыйть мәкаләсе «Төркият мәҗмугасы»ның 1925 елда басылган беренче кисәгендә чыга.—*Г. Б.*

[3] Бу турыда искә алынган француз кешесе болай дип яза: «Il prépare sur elle (il vaut dire: sur la race turque—A. B. T.) un livre «Considérations sur le passe, le present et le rôle historique de la race turque».—*Г. Б.*

[4] Профессор Фендекоглы З. Фәхри үзенең Садри Максуди турындагы бер язмасында бу әсәрнең 1928 елда нәшер ителүен күрсәтә. («Төрек йорды», 1956.—Май.—Б. 266). Әгәр бу чыннан да шулай булса, бу китапның беренче битендә Ататөрекнең 1930 елда язган сүзе урнаштырылуын ничек аңлатырга?—*Г. Б.*

һәм культурасы белән Аурупа халыкларын таныштыру. Шул Милли-мәдәни мөхтәрият планнарыннан ерак тормый. Гаиләсе Берлинга килеп җиткәнче үк Хельсинки мөселманнары имамы Вәли Әхмәт Хәким үзенең 1922 ел, 18 апрелендә язган хатында, мондый җәмгыять төзелсә, аның белән Милли идарә рәисе С. Максуди һәм аның аркалашлары җитәкчелек итәргә тиеш, дип яза һәм бу шәхесләрнең таланты, авторитеты бу һәйәтнең хәлен һәм эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итәчәк, файдалы булачак дип чыга. Бу һәйәт каршында матбугатнәшрият һәм сәүдә эше белән шөгыльләнүче бүлек тә ачу планлаштырыла. Бу һәйәтнең оешу, беренче адымнарын башлап җибәрү өчен Финляндиядә яшәүче казанлылар ярдәме булу күздә тотыла һәм киләчәктә алар акционерлык җәмгыяте төзеп аның матди ягын кайгыртырлар дип уйланыла. Имам Вәли Әхмәт Хәким бу эшкә бик теләп тотынса да, ул тиешле нәтиҗәләр бирми.

1923 елның июль ахырында, мин Финляндиядән Берлинга килгән вакытта, С. Максуди үзенең гаиләсе белән шәһәрнең дачалар бистәсе булган Панкоф урамында тора иде.

БЕР ИСКӘРМӘ

Берлинга килгәч, Садри Максуди мине үзләренә, Панкоф урамында тора торган җиренә чакырды. Бу аш мәҗлесенә Фуад Туктаров белән Гаяз Исхакый да чакырылган икән. Максудиның хатыны кунакчыл, ачык йөзле мөхтәрәм Камилә ханым кунаклар өчен күп итеп «Төркестан пылауы» пешергән. Безгә, Берлинның арзанлы ашханәләрендә тамак туйдырып йөрүчеләр өчен, өй шартларында, тәмле итеп әзерләнгән пылау җәннәт ашы кебек тәмле булды. Өстәлдә тау кебек итеп куелган бу пылауны без, ач бүреләрдәй, күз ачып йомганчы диярлек сыпырып та куйдык.

Шушы елның сентябрендә миңа Берлиннан китәргә туры килде. Аның үзенә бер сәбәбе бар иде. Большевиклар режимыннан качып киткән эмигрант буларак мин «ватансыз кеше»—Heimatlos дип хисаплана идем. Документым да «Нансен паспорты» гына иде.

Германиянең Финляндиядәге илчелегендә миңа Алман илендә барлыгы 15 көн яшәр өчен генә виза бирелгән иде. Мин визамны озайтырга тырышып карасам да, ризалык ала алмадым. Җирле полиция участкаларында минем визамны бер-ике көннән артыкка озайтмадылар. Бу заманда Берлинда

безнең якташыбыз Галимҗан Идриси эшли иде. Ул биредә «Ислам талипләренә ярдәм җәмгыяте» дә оештырган, моңа официаль рөхсәт тә алган, немец властьларына таныш, билгеле кеше була. Миңа шушы кешегә мөрәҗәгать итәргә тәкъдим иттеләр, ул гына ярдәм итә алыр, диделәр. Шушы мәсьәлә буенча аңа Фуад Туктаров барып чыга. Идриси шуннан соң мин яши торган пансионга үзенең бер кешесен—Бәдри Сәйфелмөлекоглыны җибәрде. Бу кеше миңа, әгәр мин сәяси эшчәнлеккә катнашмаска имза бирсәм, Идриси әфәнде бу эшкә керешергә риза икәнлеген әйтте. Бәдри әфәндегә мин бервакыт сәясәт белән шөгыльләнгән кеше түгел, шулай да мондый шартны кабул итә алмыйм дидем.

Германиянең куркынычсызлык даирәләре паспортым Германиягә сәяхәт өчен генә бирелгән, паспорт иясенең биредә яшәү өчен калырга хокукы юк диеп паспортыма пичәт суктылар.

Әгәр Галимҗан әфәнде исән икән, бу юлларны укыгач аның колаклары кызарыр иде, дип уйлыйм. Без соңыннан Б. Сәйфелмөлекоглының Советлар берлегенә кайтуын, кайтуга кулга алынуын һәм даны чыккан Соловкига сөргенгә куылуын ишеттек. Кызганыч! Берни эшләп булмый.

Мин кире Финляндиягә кайттым. Максуди гаиләсе белән Парижга күчеп китте. Сорбонна университетының Әдәбият факультеты каршындагы Ислам илләрен өйрәнүче институтка эшкә керде. Эшкә керүе 1923 елның ноябрендә.

1924 елның октябрендә Төрек Очагы җәмгыяте аны Төркиягә лекцияләр укырга чакыра. Биредә ул Мостафа Кемал—Ататөрек белән таныша. Бу танышу, аралашу Ататөректә бу зыялыга карата зур уңай фикер уята, ул аңа гаиләсе белән Төркиягә күчеп килергә тәкъдим ясый. Менә шуның нәтиҗәсе буларак аңа, Парижда яшәгән гаиләсе белән, 1925 елда Төркия гражданлыгы бирелә.

САДРИ МАКСУДИ ТӨРКИЯДӘ

С. МАКСУДИ—ПРОФЕССОР

1925 елның июлендә С. Максуди гаиләсе белән Төркиягә күченеп килә һәм Анкара шәһәрендә туктый. Хәмидулла Сөбхи бәйнең Мәгариф министрлыгы каршындагы Әсәр вә Тәрҗемә комиссиясенең әгъзасы итеп алына. Бу кеше озакламый министрлыктан китә һәм күрсәтелгән комиссия дә таркала. Шуның аркасында С. Максудины әле генә ачылган Хокук мәктәбенә укытучы итеп билгелиләр. Русиядә укытучылык, фәнни эш белән шөгыльләнмәгән С. Максуди бу эшләргә җиң сызганып керешә, Аурупада башлаган фәннитикшеренү эшләрен киңәйтеп җибәрә, кыска гына вакыт эчендә берничә фәнни хезмәтләр дә бастыра, шул ук вакытта илнең иҗтимагый һәм фәнни эшләренә актив катнаша башлый, күренекле дәүләт эшлеклеләре белән таныша, аралаша.

Ататөрек аның белән киңәшләшә, официаль оештырылган зур банкетларга чакыргалап тора. Кыскасы, ул яңа ватан шартларына тиз ияләшә, һәм аңа файдалы булу өчен, илнең мәдәниятын-фәнен күтәрү буенча көчен кызганмыйча эшли.

Аның кызы Адилә Аида бу еллар турында болай дип яза: «1928 елдан 1938 елга хәтле минем әтием илдә башланган төрле мәдәни үзгәрешләрдә үзенең идеяләре, тәкъдимнәре, проектлары белән дә актив катнашты, төрек телен реформалау өлкәсендә дә аның өлеше зур, боларны раслый торган документлар тулып ята»[1].

Садри Максуди миңа язган бер хатында «Turk Tarih Kurumu»—Төрек тарих җәмгыяте «Turk ocaklari» (Төрек милли-

---

[1] Адилә Аиданың инде искә алып үтелгән «Әтием—Садри Максуди» дигән мәкаләсеннән.—*Г. Б.*

мәдәни мәгърифәте оешмасы) оештырган конгресста минем тәкъдимем буенча төзелде дип яза. 1929 елда С. Максуди бу оешманың Тулы хокуклы әгъзасы итеп тә сайлана.

С. МАКСУДИ—МИЛЛӘТ ВӘКИЛЕ, ДЕПУТАТ

Мәрхүм С. Максуди Төркиядә ике тапкыр Төркиянең Милли мәҗлесенә депутат булып сайланды. Беренчесендә Шибин Карахисар сайлау округыннан (1930—1934 еллар), ә икенчесендә Трапезунд сайлау округы буенча (1934—1938). 1936 елда С. Максуди Милләтләр Лигасының Лондонда, Глазгов шәһәрендә үткән Конгрессында катнаша, 1937 елда шушы Лига миссиясе составында Чехословакиядә була.

1938 елда Ататөрек вафат була, дәүләт башына Исмәт Иненю партиясе килә. Бу шартларда Ататөрек сәясәте тарафдары С. Максуди инде яңа сайлауларда Милли мәҗлескә депутат булып үтми.

С. Максуди Ататөрек Хокук мәктәбендә (соңыннан ул университетның Хокук факультетына әйләнә) унсигез ел буе укыта, фәнни тикшеренүләр алып бара, ә 1943 елны Анкарадан Истанбулга күчеп килә. Биредә аңа ординар профессор исеме бирелә. Биш елдан соң, 1950 елда, Анкара сайлау округының демократлар партиясе исемлеге буенча яңадан Милли мәҗлескә депутат итеп сайлана. 1954 елда депутат булып сайлана алмый.

КЕЧКЕНӘ БЕР КАЗА

С. Максуди табигате белән сәяси эшлекле, бу өлкәдә тәҗрибәле шәхес булса да, бер тапкыр ул «бер кечкенә каза»га очрый. Бу инцидент турында аның кызы Адилә Аида инде күрсәтеп үткән мәкаләсендә бу «каза»ның «Диңгезбанк» термины белән бәйләнгән булуын күрсәтә. Оста сәясәтче нинди «хата» җибәргән соң?

Милли мәҗлеснең бер утырышында яңадан ачылган Төркиянең Үзәк пароходлык банкасына нинди исем бирү мәсьәләсе карала. Аңа «Диңгезбанк» исеме бирү тәкъдиме ясала. Төрек телен һәм грамматикасын тирән белмәгән аерым депутатлар бу тәкъдимне яклап чыгалар. Утырышта С. Максуди да сүз ала һәм бу атаманың төрек теле табигатенә, аның фонетикасына туры килмәвен күрсәтә. «Диңгез банк» (Диңгезбанк) исеме урынына «Диңгез банкасы» дип атау дөрес булыр дип чыга.

Трибунадан төшеп житми, аның бу тәкъдименә каршы кычкыра башлыйлар: «Сез нәрсә эшләгәнегезне аңлыйсызмы, бу исемне Ататөрек үзе тәкъдим итте»,—диләр. Максуди аларга: «Кычкырудан ни файда, дөреслек һәр нәрсәдән өстен» дип җавап кайтара.

С. Максудиның мондый туры җавабы Милли мәҗлесне уңайсыз хәлдә калдыра. Аның җитәкчеләренең дә күңеленә ошамый. Мәсьәләне карау өчен махсус комиссия оештырыла.

Икенче көнне Милли мәҗлес утырышында С. Максудига отпор бирер өчен анда популяр депутат хисапланган Исмәгыйль Муштак Маякон һәм Хәсән Рәшид Танкут алдан ук бик нык хәзерләнеп киләләр. Мәҗлестә, дипломатик этикет саклаган формада, «Диңгезбанк» сүзе ул чип-чиста төрекчә, төрек теленең грамматика һәм фонетикасына тулысынча туры килә дип бөтен көчләре белән депутатларны ышандырырга, бу терминны кабул итәргә бик тырышып карыйлар.

Максудига басым моның белән генә чикләнми. Шул ук көнне Төркия радиосы «юридик фәннәр профессоры булган бу депутат бөтен яктан профан, төрек телен белми, сай фикерле, дилетант» дип аңа каршы бөтен илне котыртырга тырыша. Бу кампанияне оештыручыларның иң активы Кырым төрекләреннән булган, Көтахиядән сайланган депутат Вәдит Үзгүрен белән үзен төрек дип йөрткән әрмәнле депутат Дилачар (Агоп Мартаян) булалар. Бу тапшыруга килгән Киршәһәр депутаты Мөфит Үздәш илә мөхәррир Фалих Рифки Атай үзләренең чыгышларында объектив булып калырга тырышалар.

«Диңгезбанк» тирәсендәге күңелсезлекләр озакка сузылмый, Садриның хаклыгы таныла, бу бәйләнүләр аның дәрәҗәсен төшерә алмый. Ничек кенә булмасын, бу хәлләрне ул авыр кичерә.

Шушы хәлләр уңае белән трабзонлы[1] Наил Нихад Бозтәпә исемле шагыйрь Мәҗлес депутатларын тәнкыйть итеп сигез куплеттан торган «Вакыйга» исемле, тиз популярлык алган сатирик шигырь дә язып чыга[2].

С. Максудига каршы бу ямьсез нәрсәләр, аны хурларга тырышулар Истанбул универститы юридик факультеты про-

---

[1] Трабзон—Төркиянең бер шәһәре.—*Ә. К.*

[2] Бу шигырь Н. Н. Бозтәпәнең 1957 елда Истанбулда «Агач касидәсе» исеме белән чыккан җыентыгында басыла. (Б. 33—34).—*Г. Б.*

фессоры булып эшләгән вакытта оештырыла. Ул гына да түгел, бу вакытта аның «Төрек дили өчен» дигән, Ататөрек тарафыннан югары бәяләнгән, төрек теле белгечләре тарафыннан да танылган китабы басылуга инде җиде ел, ә Төрек тарих җәмгыятендә ясаган тарихи чыгышыннан соң—кыскасы, илнең зур галиме булып танылган көннәрдә оештырыла. Ә бу җәмгыятьне оештырган конгресста С. Максуди «Тарих гамәлләре» дигән темага доклад ясаган иде, бу доклад зур игътибар казанган һәм югары бәя алган иде.

С. Максуди юкка гына Ататөрекнең якын күргән галимнәре арасында иң хөрмәтлеләрнең берсе булмаган. Мәсьәләнең бөтен сәерлеге дә менә шунда инде. Ул гына түгел, бу кампаниягә аерым матбугат органнары да килеп кушыла. Кайбер газеталар С. Максудины «наданлыкта», төрек телен белмәүдә, тагын нәрсәләрдә генә пычратып күрсәтергә тырышмадылар.

Ассызыклап әйтеп үтү кирәктер: бу чатрак «Диңгезбанк» профессорга бик күп борчулар алып килде. Дөрес, шул хәтле шау-шу күтәргән бу термин тиздән тулысынча кире кагылды һәм Милли мәҗлес С. Максуди тәкъдимен искә алып «Диңгезчелек банкасы» терминын кабул итте.

ӘСӘРЛӘРЕ

Русиядә С. Максуди иҗат, язу-сызу белән аз шөгыльләнә. Яшь чагында язган, Казанда басылган «Мәгыйшәт» хикәясе[1], Дума депутаты булган вакытта Дәүләт делегациясе составында Англиягә баруын, андагы сәяхәтен тасвирлаган «Англиягә сәяхәт» әсәре—Русиядә басылган китаплары шулар белән чикләнә. Иҗади эшкә, китаплар, мәкаләләр язуга С. Максуди ныклап торып Төркиягә күчеп килгәч кенә керешә. Төркиядә, Анкара һәм Истанбулда аның түбәндәге әсәрләре аерым китаплар булып басылып чыктылар:

1. Төрек дили өчен. 1931.
2. Хокукның гомуми нигезләре. 1937.
3. Англиядә халык хокукы. 1940.
4. Хокук тарихы буенча дәресләр. 1941.
5. Хокук тарихы фәлсәфәсе. 1946.
6. Хокук фәлсәфәсе. 1946.
7. Гомуми хокук тарихы. Өч басма: 1944, 1946, 1948.
8. Төрекнең тарихы һәм хокук (Исламияткә хәтле чор). 1947.
9. Миллият тойгысының социологик нигезләре. 1955[2].

Төрек тарихын язу өлкәсендә ул, Ататөрек инициативасы белән оештырылган план буенча, «Төрек тарихының башлан-

---

[1] Ул ике тапкыр басыла: 1898 һәм 1914 елларда.—*Ә. К.*

[2] Бу хезмәт тагын ике тапкыр, 1957, 1979 елларда кабат чыга. Бу исемлеккә С. Максудиның чит илләрдә чыккан барлык әсәрләре дә тулысынча теркәлмәгән. Алар:

1. Төрек хокук тарихы. 1928.
2. Искитләр—сакалар. 1933.
3. Урта Азия төрек дәүләтләре. 1934.
4. Теократик дәүләт вә лаеклы дәүләт. 1940.
5. Фарабиның хокук фәлсәфәсе. 1945.
6. «Кутадгу-билиг»кә багышланган әсәре. 1947.—*Ә. К.*

гыч чорлары» дигән коллектив хезмәтне язуда да катнаша. Аның бу серия буенча ике хезмәте басылуы билгеле[1].

С. Максуди үзенең хезмәтләре белән фәнни журналларда да, башка вакытлы матбугатта да шактый актив катнаша. Бу хезмәтләрен барлау, исәпкә алу, тасвирлау эшенә аның мөхтәрәм кызы Адилә Аида кереште[2].

1954 елның 10 сентябрендә без (соңгы тапкыр—*Ә. К.*) Босфор буендагы Әмиргандаки Чинаратлы кәһвәханәсендә очрашып, чәйләр эчеп озак сөйләшеп утырдык. Шунда ул миңа үзенең мемуарлар яза башлавы турында да әйтте. Аннан соң ел ярым вакыт узып китте. Ул мемуарларын язып бетердеме, юкмы—мин моннан хәбәрдар түгел. Үзенең тәрҗемәи хәлен язып калдырган булуын мин бик теләр идем. Аның мемуарларының тарих өчен гаять кызыклы, әһәмиятле чыганак булуы турында шикләнмәскә мөмкин.

---

[1] Ул хезмәтләр, күрәсең, аерым китаплар булып та чыккан булса кирәк. Искәрмәдәге исемлектә 2, 3 номерлар астында күрсәтелгән хезмәтләр әнә шул план буенча башкарылганнар.—*Ә. К.*

[2] Бу юллар С. Максуди вафатыннан соң 1957 елда язылганнар. Кызының «Садри Максуди Арсал» дигән 290 битле монографиясе 1991 елда Анкарада аерым китап булып басылды. Анда С. Максуди хезмәтләре шактый киң искә алынган. Ләкин барысы да түгел.—*Ә. К.*

С. МАКСУДИНЫҢ ТӨРКИЯДӘ ЧЫККАН БЕРЕНЧЕ ҺӘМ СОҢГЫ ӘСӘРЛӘРЕ ТУРЫНДА

Мәрхүмнең Төркиядә беренче фәнни эшчәнлеге милли тел мәсьәләләренә карый. Милли тел һәм миллият мәсьәләләре аның иҗатында зур игътибарга лаек булган өлкәләрнең берсе. Шушы ике өлкә—тел һәм тел тарихы—аның фәнни эшчәнлегендә зур урын тота.

С. Максудиның Төркиядә басылган беренче китабы «Төрек дили өчен», ә соңгысы «Миллият тойгысының социологик нигезләре» дигән исемнәре дә шул турыда сөйли. Бу ике әсәргә аның иҗаты белән кызыксынучыларга аерата игътибар итүләрен теләр идем. Шул максаттан чыгып без дә шушы ике китапка аерым тукталып үтәргә булдык.

1. «ТӨРЕК ДИЛИ ӨЧЕН»

Югарыда искә алган идек: бу әсәрне автор Аурупада яза башлый, Төркиядә тәмамлый. Төркиягә килгәч ул әсәрен тулыландыра, киңәйтә. Моның шулай икәнен аңлау авыр түгел: Төркиягә ул 1925 елда килә, ә китап шуннан соң алты ел үткәч, 1931 елда басылып чыга.

ПРОФЕССОР ФЕНДЕКОГЛЫ НӘРСӘ ДИ

Төркиягә килеп яши башлау белән С. Максудины Гази Мостафа Кемал үзе җыя торган софраларга (банкет-очрашу, киңәшмә) чакырып тора. Профессор Фендекоглы бу турыда болай дип яза: «Профессор Садри Максуди 1925 (1928 елдан—*Г. Б.*)—1938 еллар арасында Анкарада сәяси, фәнни эшлекләләр белән үткәрелә торган софраларда катнашып килде. Аерым мәсьәләләрне караганда аның фикерләре һәм тәкъдим-

нәренә зур игътибар бирәләр иде. Мәсәлән, төрек теле өлкәсенә караган мәсьәләләрдә. Аның 1928 (1931—Г. Б.) елда чыккан «Төрек дили өчен» дигән китабы милли телне камилләштерү өлкәсендә эшчәнлегенең бер мисалы булып тора» (Кара: «Turk yurdu».—1957.—Март.—Б. 266).

Кызы Адилә Аида да «С. Максудиның «Төрек дили өчен» дигән әсәренең төрек телен реформалауда тоткан ролен раслый торган бик күп документлар бар»,—дип яза. (Кара: «Җөмһүрият» газетасы.—1957.—1 март.)

К. БРОКЕЛЬМАН БӘЯЛӘРЕ

Инде әйтеп үтелгәнчә, бу әсәр Аурупада языла башланса да, аның асылын С. Максуди Төркиядә тәмамлый. Германиянең атаклы арабист һәм тюркологы, профессор К. Брокельман аңа беренчеләрдән булып югары бәя бирә. Бу китап хәтта аның кереш сүзе белән басыла. Анда шундый юллар бар: «Садри Максуди үзенең бу хезмәтендә төрек теленең үткәне һәм хәзерге хәле турында төрле яктан килеп анализ ясый. Шулай ук төрек теленә ислах ясау һәм киләчәктә төрек әдәби теленең үсеш юллары мәсьәләләрен яктырта. Аның бу өлкәдәге тәкъдимнәре зур игътибарга лаек. Хезмәтнең аерата әһәмиятле яклары турында без инде өстә тукталып киттек. Яңа Төркиядә Садри Максуди тәкъдимнәрен һәм киңәшләрен тормышка ашыру өчен тиешле җирлек һәм мөмкинлекләр дә бар дип ышанасы килә».

АТАТӨРЕКНЕҢ ВАСЫЯТЕ

С. Максудиның бу китабы президент Мостафа Кемалның 1930 ел, 2 сентябрь тарихлы кереш сүз белән башлана: «Милли хис белән милли тел арасындагы бәйләнеш гаять зур көчтер. Миллиятлек һәм милли тел—милли хис һәм милли аңны үстерүдә хәл итүче рольне уйнаучы җирлекләр. Төрек теле дөньяда иң бай телләрнең берсе. Аның үсеше өчен тиешле шартлар булуы гына кирәк. Үзенең илен, үзенең ватанын авыр көрәшләрдә яклый, саклап кала алган төрек милләте үзенең милли телен чит телләр басымыннан да саклый алачак.—Гази М. Кемал»[1].

[1] Олы Гази ул заманда әле Ататөрек дигән атаклы исем йөртми иде.—*Ә. К.*

Брокельманның С. Максуди хезмәтенә югары бәясе әле ул китап булып чыкканчы язылган була. Бу әсәр басылып чыгуга инде 25 ел үтсә дә, Төркиядә тел галимнәре, лингвистлар бу хезмәткә тиешле тирән анализ һәм бәя биреп җиткермәделәр. Киресенчә, авторның төрек телен реформалау, камилләштерү, сүзлек составын, үстерү, чит телләр сүзләренә карата булган тәкъдимнәрен, киңәшләрең тәнкыйть итеп чыгучылар күп булды.

Бөек Газиның үз инициативасы белән төрек теленә ислах ясарга кирәклеге көн тәртибенә куела һәм аны тормышка ашыру өчен «Тел һәйәте»—комитеты да оештырыла. Менә шуңа күрә алар төрек теленә ислах ясау мәсьәләсенә каршы турыдан-туры чыга алмыйлар, ә икенче юл белән—С. Максуди китабын тәнкыйть итү юлына басып, бу реформага карата үзләренең кире караштa булуын астыртын белдерәләр. Төрек теленә ислах кирәклеген аңлаучылар булса да, алар бу турыда эндәшми торуны мәслихәт саныйлар. Алар ни өчен С. Максуди тәкъдимнәрен яклап чыкмаганнар соң? Моны аңлау бик читен.

Бу китап турында бернәрсә дә язып чыкмадылар дию дөреслеккә туры килмәс иде. Андый мәкаләләрнең авторлары тел белгечләре, галимнәр түгел, ә сәясәтчеләр, журналистлар иде.

Бу китап турында мин белгән мәкаләләр түбәндәгеләр:

1. «Акшам» газетасының 1931 ел, 6 март санында Ва-Ну имзасы белән басылган кечкенә генә бер мәкалә. Анда китапка бәя түгел, аның эчтәлеге турында гомуми сүзләр белән чикләнелгән.

2. «Җөмһүрият» газетасының 1931 ел, 15 март санында басылган Йосыф Османның бу китапка уңай бәя биргән рецензиясе.

3. «Вакыт» газетасының 1931 ел, 24, 26 саннарында бу юлларның авторының ике мәкалә-бәяләмәсе дөнья күрде.

Болардан тыш Җәфәр Сәетәхмәтнең (чыгышы белән Кырымнан) «Миллият» газетасының 1931 ел 24, 26 апрель саннарында ике мәкаләсе басылды. Җәфәр бу китапка, чит илләрдә яшәүче төрки халыкларының милли-сәяси эшлеклесе буларак, милли телләрне яклау, саклау мәсьәләләренә туктала. Мәсәлән, ул «мәдәниятлы тел»не яклау турында, алга киткән бер телнең икенче тел тарафыннан әкренләп йотылу куркынычы турында сүз алып бара. Ул авторның, төрек теленең башка төркиләр өчен дә уртак телгә әверелүе мөмкин,

дигән концепцияне кабул итми. Дөньяда башланган үзгәрешләр нәтиҗәсендә башка төрки халыкларның да милли аңнары уяна башлады, бу шартларда гомуми бер уртак тел урнашуы идеясенең киләчәге ышанычсыз дип карый. Ж. Сәетәхмәт авторның башка илләрдә яшәүче төрки халыкларның телләрен тикшерү, аларның үз телләренең киләчәген кайгырту кирәклеге мәсьәләләренә тукталмавын тәнкыйть итә.

II. «МИЛЛИЯТ ТОЙГЫСЫНЫҢ СОЦИОЛОГИК ӘСАСЛАРЫ»

Бу—С. Максудиның соңгы, аның иҗатының йөзек кашы булган әсәре. Ул үзе дә бу хезмәтнең гаять актуаль, әһәмиятле булуын искәртеп үтә. Китапта язган кереш сүздә ул: «Безнең телебездә (Яңа Төрек телендә) генә түгел, Аурупа тел белгечләре дә милли мәсьәләнең социологик нигезләрен өйрәнүгә багышлап хезмәт язганнары юк әле», ди.

Мәсьәләнең актуаль темага язылуына карамастан, төрек матбугатында бу хезмәт турында зурдан сүз әйтү булмады. С. Максудиның Истанбулда, Копак отелендә зур банкет җыюы, аңа күп кенә галимнәр, лингвистлар, журналистларны чакыруы, минем фикеремчә, әнә шуннан чыгып—яңа хезмәте белән җәмәгатьчелекне таныштыру йөзеннән дә оештырылган иде.

С. Максуди вафат булуга өч көннән соң профессор Фәһри Фендекоглының дөнья күргән мәкаләсендә: «Максуди пенсиягә чыккач та тик ятмады, фәнни эшен дәвам итте, соңгы китабын басу белән дә мәшгуль булды. Бу китап чыккач аның белән кызыксынучылар булмавын күргәч, аңа битараф калмастай кешеләр белән очрашу өчен оригиналь юл тапты. Шушы очрашуда бу китап турында фикерләр алышу да булган, күрәсең, һәм шуның нәтиҗәсе буларак, бу әсәр турында матбугатта сүз кузгалып китте. Автор үзенең соңгы көннәрендә бу әсәрен француз теленә тәрҗемә итәргә керешә. Үзенең соңгы көннәрендә гаиләсенә: «Бу эшне дә тәмамладым»,—дигән[1].

Бу хезмәтемнең «А» бүлеген Садри Максудиның үз сүзләре белән тәмамлыйсым килә:

---

[1] Төрек йорды.—1957.—Май.—Б. 646.—*Г. Б.*

«Мин язучы да, стилист (журналист—Ә. К.) та түгел, мин төрек халкының үткәнен һәм хәзерге хәятен өйрәнүче төрек кешесе, халкымның зур цивилизациясе һәм бөек мәдәнияты үткән юлны ачыклаган һәм шул зур тарихны үземнең хезмәтләремдә тасвирлаган кеше»[1].

Бу сүзләр С. Максудиның үз эшчәнлегенә үзе биргән, чынбарлыкка туры килә торган бәядер.

[1] «Төрек дили өчен» басмасының «Башлангыч» бүлегеннән.—*Г. Б.*

ӘХМӘТҺАДИ МАКСУДИ[1]

I. ЧЫГЫШЫ ҺӘМ БЕЛЕМ АЛУЫ

Низаметдин Максудиның олы улы Әхмәтһади 1867 еллар тирәсендә, инде искә алынган авылда, дөньяга килә. 13—14 яшьләрендә этисе аны Казанга алып барып Габделгалләм Салихоглының Күл Буе исемле мәдрәсәсенә укырга китереп куя[2]. Ул бик зиһенле бала булып чыга. Иске мәдрәсә диварларына гына бикләнеп, иске ысуллар белән генә чикләнми. Шәһәрне икегә бүлгән, мөселманнарны урыслардан аерып тора торган Булак елгасының икенче, урыслар ягына да барып чыга, алар дөньясы белән дә таныша башлый. Казан университеты һәм урыс җәмгыятенең хәлләре белән дә кызыксына.

Шәкертлек елларында мәшһүр төрек Исмәгыйль бәй Гаспралының «Тәрҗеман» газетасын, татар басмаларыннан тыш, Истанбулда басылган китапларны яратып укый. Урыс телен үзлегеннән өйрәнә башлый, соңыннан аны аерым укытучы яллап үзләштерүгә керешә. Тормыш, яшәеш турында уйлана, дөньяны киңрәк таный башлый, күзләре киңрәк ачыла бара.

II. «ЫСУЛЕ ҖӘДИД»ЧЕ

Ә.-Һади Максуди иске, кадими мәдрәсәләрдә укытуының тормыштан ераклашканын, артта калуын күрә; яңача, җәдидчә укыту, тормышка файдалы белем бирә торган уку-укыту юлын сайлый. Шуңа күрә булса кирәк, ул мәдрәсә

---

[1] Г. Баттал аның исемен төрле формаларда яза: Һади әфәнде, Әхмәтһади Максуди, Һади Максуди дип тә. Ничек язылган булса, бирედә дә шул язылыш белән китерелә.—*Ә. К.*

[2] Ә.-Һади Максуди «Мәрҗани» дигән җыентыкта (Казан, 1915.—Б. 432) үзенең бу мәдрәсәгә 1881 елда укырга керүен искә ала.—*Г. Б.*

шәкертләре кебек мулла булу, мәдрәсәләр ачып дини фәннәр генә укыту юлын түгел, «учительлек» юлын сайлый. Шуңа ул укытуның яңа юлларын өйрәнә. Шушы вакытта аңа Бакчасарайдагы Зинҗәрле мәдрәсәсеннән гарәп теле укытучы сыйфатында чакыру килеп төшә. Бирегә килгәч ул Исмәгыйль бәй Гаспралы илә таныша, аның яңача, җәдидчә укыту методларын, нигезләрен өйрәнә. Гаспралының «Хуҗа-и сыбьян» исемле җәдидчә ысул белән язган китабына ияреп, Казанга кайткач «Мөгаллим әүвәл», «Мөгаллим сани» исемле уку китаплары яза. Бу китаплар бик тиз популярлык казаналар һәм шуның белән канатланган автор «Ысулы җәдид» мәктәпләре өчен башка фәннәр буенча да яңа төр дәреслекләр язуга керешә. Ул чын мәгънәсендә ысуле җәдид нигезендә, яңача укытуга нигез салучы остазлардан була.

Ул ысуле җәдид методы буенча укытучылар тәрбияләүгә дә, яшь муллалар арасында бу методны тормышка ашыручылар әзерләүләргә дә күп көч куя. Бу яңа методны гамәлгә кую өчен татар байлары, сәүдәгәрләре арасында да аңлату эшләре алып бара, аларның ярдәмнәрен дә күрә.

Шундый шартларда ул яңа мәктәп өчен төрле фәннәр буенча яңа дәреслекләр язу эшенә актив керешеп китә. Аның әсәрләре басылып тора, яңаларын яза... Табигате белән практик, эш кешесе, укыту буенча зур тәҗрибәле бу фидакарь зыялы яңа дәреслекләр язу белән бергә төрле уку-укыту әсбаплары да яза, укыту өлкәсендә яңа методлар кертеп тора, җәдидчелекне ныгыту, тарату өчен туктаусыз эш алып бара.

Бу чорда ысуле җәдидчә укыту түбәндәге юнәлешләрдә үсә барды:

1. Туган телдә укырга һәм язарга өйрәтү.
2. Дин нигезләре буенча белем бирү.
3. Гарәп теле нигезләрен үзләштерү.
4. Дәүләт теле булган урыс телен җиңел методлар белән укыту, үзләштерү.

Ул шушы өлкәләрнең һәрберсе буенча да китаплар яза, мәктәп китабы һәм педагогикасына да зур өлеш кертә.

Аның дәреслекләре нихәтле популяр булуы турында аның әсәрләренең бер-бер артлы басылып килүе дә ачык сөйли. «Мөгаллим әүвәл», «Мөгаллим сани» дигән төрек теле буенча дәреслекләре бөтен мәктәпләргә үтеп керде, җәдидчә укытуның җиңеп чыгуында зур роль уйнады. Аның «Сарыфи

төрки», «Нәхүи төрки» дигән китаплары Казан төрки теленең грамматикасы, синтаксисы буенча укыту өчен яңа төр дәреслекләр иде. Грамматика буенча бу китапларның туган тел закончалыкларын фәнни нигезләү буенча да әһәмияте зур иде.

Күренекле мөхәррир Җамалетдин Вәлиди, «бу китаплар туган телебезне өйрәнү өлкәсендә чын мәгънәсендә фәнни хезмәтләр дә булды», дип язды.

Шулай итеп, Ә.-Һ. Максуди телебезне фәнни яктан өйрәнү һәм аны үстерү мәсьәләләренә дә зур игътибар бирә. Үзенең бу китаплары һәм күпсанлы мәкаләләрендә телебезнең категорияләрен аныклау һәм унификацияләү, Казан төрки теленең имлясын камилләштерү, телдә буталчыкларга сәбәп булучы «иске төрки тел» элементларыннан котылу, язуда яшәп килгән аермалыкларны, телебезне укытуда киртә булып килгән каршылыкларны бетерү, телгә ислах ясау нигезләренә дә туктала. Һәм ул аларны тормышка ашыру буенча да зур эшләр башкара. Үзенең «Йолдыз» газетасы битләрендә телебезне үстерү, камилләштерүгә багышланган мәкаләләр бастырып тора, тел мәсьәләсенә караган бәхәсләргә күп урын бирә. Шуның өстенә ул үзенең дәреслекләренең телен туган телне камилләштерү буенча үзе куйган принциплар буенча язып килә.

Казан шивәсенә нигезләнгән бу телне Ә.-Һ. Максуди «татар теле» дип тә, «төрек теле» дип тә атамый, аны үзенчә «төрки тел» дип билгели. Әгәр мин аны «төрек теле» дисәм, патша цензурасы миннән пантюркизм эзли башлавы бар дип карый. Ә «төрки» дигән термин бездә, Урал, Казан якларында борын-борынгыдан таралган, шуңа күрә ул безнең милләтебез өчен ят сүз түгел, ди. Телебезгә нинди исем бирү мәсьәләсендә Ә.-Һ. Максуди әнә шулай сак килгән.

Өстә күрсәтелгән икенче юнәлештә ул дистәгә якын китап яза. Ә өченчесе—гарәп телен укыту буенча аның «Истифак» (Башлангыч уку), «Истикмаль» (Тәгәлләүче уку) исемле китаплары бар[1].

Дүртенче юнәлеш—урыс телен укыту буенча аның яңа метод белән язылган, «Русистан» исеме астында дүрт китап булып чыккан дәреслеге бар[2].

---

[1] Моннан тыш бу өченче юнәлеш буенча аның «Шифаһия» исемле китабы да булган.—*Ә. К.*

[2] Урыс теле укыту буенча бу дәреслектән тыш ул француз телен өйрәтү буенча «Френжистан» исемле китап та язган.—*Ә. К.*

Ә.-Һ. Максудиның мәдәният, педагогика, мәктәп өлкәсендәге хезмәте Казан төркиләре өчен генә түгел, күп кенә башка төрки халыклар культурасы өчен дә гаять әһәмиятле, файдалы була. Бу китаплар күп кенә төрки халык укучыларының юлбашчысы, туган телне гамәлгә кертү, дөньяви белемнәр бирүдә юлдашчылар булдылар.

Шимали төрекләре тормышында зур роль уйнаган бу мөхтәрәм һәм мәшһүр зыялының эше һәм исеме мәдәниятыбыз, мәгърифәтебез мәйданында югары бәяләнергә тиеш, аның исеме бервакытта да онытылмас.

Аның ысуле җәдид, яңача укыту, педагогика, тел өлкәсендәге эшчәнлеген тасвирлауны шуның белән тәмамлыйбыз.

III. ЖУРНАЛИСТИКАДА ЭШЧӘНЛЕГЕ

ӘХМӘТҺАДИ МАКСУДИ—«ЙОЛДЫЗ»ЧЫ

1905 елгы революция Русиянең төрки халыкларына да вакытлы матбугат оештыру хокукын бирде. Шуның нәтиҗәсе буларак, Казанда төрек телендә беренче булып «Казан мөхбире» исемле газета да дөнья күрде. Аның хуҗасы адвокат Сәетгәрәй Алкин, ә баш мөхәррире күренекле фикер иясе, мәшһүр Йосыф Акчура иде. Газетаның беренче саны 1905 елның 29 октябрендә чыкты. Русиядә төрек телендә газеталар 1906 елдан бер-бер артлы чыга башлыйлар. 1906 елның 15 январенда Ә.-Һ. Максудиның «Йолдыз» газетасы да дөнья күрә. Газетаның беренче санында редактор, «Йолдыз» газетасы төрки газетадыр, «Йолдыз» газетасы милли газета буларак оештырылды», дип яза һәм шундый гомуми сүзләр астында газетаның мәсләген билгеләүдән качарга тырыша. Ары таба: «Хәзер, мәсләкләр чуалган заманда, бер генә мәсләккә таяну, безнең карашча, мөмкин түгелдер»,—дип язган. Максудиның бу сүзләреннән заманында, «һәр газетаның үзенә бер мәсләге булса, «Йолдыз»ның мәсләге мәсләксезлектер», дигән сүзләр йөрде.

Газетаның беренче саннары кече форматта, юка журнал формасында чыга башлый, тора-бара ул бар яктан да формалаша һәм көндәлек газета булып нәшер ителеп килә. Газета 1917 ел февраль революциясеннән соң, бернинди басымнарга дучар булмыйча, үзеннән-үзе ябылды. Заманында ул Ка-

занның «Кояш» исемле газетасы белән ярыша иде, соңгысының да гомере революциядән соң киселде.

Ә.-Һ. Максудиның журналистика дөньясындагы эшчәнлеге аның педагогика, мәгърифәт өлкәсендәгеләре кебек зур булмады. Әгәр ул матбагачылыкка кермичә, журналистикага үзен бәйләмичә, бары тик педагогика, дәреслекләр язу, җәдидчелек өлкәсендә генә эшләсә, бәлки, яхшырак та буласы булгандыр. Чөнки анда журналистларга хас кыюлык, үткенлек юк иде, ул сугышчан публицист була алмады. «Йолдыз» газетасының чәчәк аткан елларында, бөек урыс революциясе көннәрендә мин бередә бераз вакыт газетаның секретаре булып эшләп алдым.

IV. «ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫ ТУРЫНДА ИСТӘЛЕКЛӘРЕМ

«ЙОЛДЫЗ» ГАЗЕТАСЫНДА НИЧЕК ЭШЛИ БАШЛАДЫМ?

Газетага эшкә кергәнче үк мин Һади әфәнде һәм аның газетасы белән таныш идем. Троицк шәһәрендә укытучы булып эшләгәндә үк газетага мәкаләләр яза башладым.

«Төрек-татар тарихы» дигән китабымны бастыру артыннан 1912 елда Казанга килгәч Ә.-Һ. Максуди белән дә шәхси таныштым. Бу елның җәй көнендә «Йолдыз»ның 1000 нче саны чыгу уңае белән бер мәҗлес-банкет оештырылган иде. «Әлфе ләйлә» исемендә үткәрелгән бу очрашуга сәяхәтче-мосафир буларак мине дә чакырдылар.

Бүген дә хәтеремдә, биредә берадәрән Шәрәфләр матбагасының күренекле нәшире вә китапчы Гыйльметдин Шәрәф көчле нотык белән чыкты, бу чыгышында милләтне агарту, аның мәгърифәтен кайгырту, киләчәге өчен бөтен көчләрен жәлләмичә эшләүче Максудиларга зур рәхмәтләр белдерде.

1913 елның июлендә хатыным белән икәүләп пароходта Казанга сәяхәткә чыктык. (Без ул вакытта икебез дә укытучы булып Троицк шәһәрендә эшли идек.)

Кайбер дусларым, шул исәптән язучы Галимҗан Ибраһимов та, миңа укытучылык эшен калдырып, Казандагы «Йолдыз» газетасына секретарь булып кер, дип димли башлаганнар иде. «Син укытучы булуга караганда, табигатең белән мөхәррир кеше. Троицк кебек бер провинциаль җирдә сүнеп китсәң, бу безнең өчен дә югалту булыр. Һади абыйның газетасы коры сүз басу белән мавыга башлады. Бар да, шул га-

зетаның секретарь вазыйфасын кабул ит тә, газетаны тәртипкә китер»,—дияләр иде.

Мин боларның сүзен күңелгә якын алып Казанга килдем, газетага секретарь булып эшкә кереп анда эшли башладым.

Һади әфәнде, һичшиксез, акыллы, дәрәҗәле һәм күп белемле кеше булса да, аңа тәвәккәллек җитми иде, артык сак, шикләнүчән иде. Билгеле булганча, яхшы газетчы-журналист булу өчен кыюлык һәм тәвәккәллек тә, үткенлек һәм батырлык та, вакыты белән оятсызрак булу да кирәк.

Мин секретарь булып эшли башлагач, газетага яңа рух, кыюлык, яңа юнәлеш бирергә, аны җанландырырга тырыштым, әмма Һади әфәнде ул-бу була күрмәсен дип элекке позицияләреннән чигенмәскә тырышты һәм шуның аркасында безнең арада каршылыклар, бәхәсләр чыгып торды.

Үзен тәҗрибәле һәм күпне белә торган кеше дип санаган Һади әфәнде белән миңа аерым мәкаләләрне басу, газетаның йөзен, юнәлешен яңарту турында еш кына бәхәсләшергә, үземнең тәкъдимнәремне фактлар белән дәлилләргә туры килә. Бу бәхәсләр, дәлилләүләр бушка китмәде, ул минем кайбер тәкъдимнәрнең дөрес һәм файдалы икәнен танып, аларны кабул да иткәли иде[1].

Нәшир-мөхәррир белән булган бу бәхәсләрдә минем фикер, тәкъдимемне яклап бер кеше дә авыз ачып сүз әйтмәде, чөнки редакция хезмәткәрләре Һади Максуди «мәктәбендә» тәрбияләнгән кешеләр иде. Газетаның секретаре булган күренекле драматург Галиәсгар Камал мин килгәч тә биредә эшләде, ләкин ул бернәрсәгә катышмый иде, тыныч кына газетага басу өчен төрле информацияләрне тәрҗемә итү белән

[1] «Төрек дили курумы» институтында эшләүче, чыгышы белән Урал якларыннан булган Габделкадыйр Инан бер мәҗлестә ясаган чыгышында минем «Йолдыз» газетасында эшләвем турында болай дип әйтеп чыкты: «Г. Баттал-Таймас 1913 елда Казанга килү белән «Йолдыз» газетасында секретарь булып эшли башлады, һәм шул заманнан башлап ул бу газетаның гамәли редакторына әйләнде. Басманың нәшире вә мөхәррире, атаклы педагог Һади Максуди «Йолдыз» битләрендә сәяси, милли мәсьәләләргә урын бирүгә караганда ысуле җәдид, халык мәгарифе мәсьәләләренә урын бирде, газетада шушы мәсьәләләрне яктырту зарури дип эш итте, матбугат өлкәсендә цензура кануннарына туры килмәве мөмкин булган әйберләрне басудан качарга тырышты. Г. Баттал исә газетага яңа рух, яңа юнәлеш бирде. Атаклы педагог-редактор, як-якка карап эш итә торган Һади Максуди белән кыю, тәвәккәл эш алып барырга яратучы Таймас (Г. Баттал) арасында, күрәсең, бәхәсләр генә түгел, фикер ягыннан да каршылыклар аз булмый. Аның 1917 елда газетадан китүенең сәбәбе дә шуңа барып тоташты булса кирәк...»—*Г. Б.*

генә мәшгуль иде. Ул бераз «әһли кәеф»—хәмер белән мавыга иде. Аның инде сәламәтлеге дә шактый какшаган, иҗат эшеннән аерыла башлаган чагы иде.

Асылы белән яхшы, хуш табигатьле Һади Максуди аратирә мөнәсәбәтле, мөнәсәбәтсез дә мактанырга, үзен зур кеше итеп күрсәтергә ярата иде. Аның бу характеры, гайре эшләре газета битләрендә басылган материалларда да чагылгалап килде. Моны күргән башка газета хезмәткәрләре бу нәрсәне үз матбугатлары битләрендә мәзәк итеп яктырталар да иде. Мондый әйберләрне мин газетада бастырмаска тырыша идем, ләкин һәрвакыт моңа көчем җитми иде. Ул үзенең сәяси, милли, икътисади темаларга язган мәкаләләрендә кыю фикерләр әйтү, нәтиҗәләр ясаудан кача, әйтәсе фикерен күчмә мәгънәсендә яисә сорау бирү формасында чагылдыра иде.

«ЙОЛДЫЗ»ДАН КИТҮЕМ

Яхшымы, яманмы, ничек кенә булмасын бу хөрмәтле, сөекле Һади Максуди белән без дүрт ел бергә эшләдек. Миңа калса, бөредә эшләү елларында мин «Йолдыз» газетасына җитдилек, кыюлык рухы бирә алдым дип уйлыйм.

Газета атнага өч тапкыр чыгып килгән булса, ул инде биш тапкыр чыга башлады, газетаның тиражы да, укучылары да, авторитеты да күтәрелде.

1917 ел революциясе килеп җитте. Газетаның горизонтын, кыюлыгын, диапазонын киңәйтү өчен киң мөмкинлекләр дә туды. Ләкин мин газетадан киттем. Шундый шартларда газетаны калдырып китүемә бер очрак та этәргеч булды.

1917 елның 16 мартында патша Николай II үзе һәм варисы Алексей исеменнән тәхеттән ваз кичте. Шул уңай белән мин бер мәкалә яздым. Аны Һади әфәнде рөхсәте белән басар өчен типографиягә илтеп бирдем. Икенче көнне газетаны карасам, минем мәкаләмне зур кыскартулар белән басуын күреп шаккатып калдым. Типографиягә барып моның сәбәбен сорадым. Бу мәкаләне «Йолдыз»га кертергә рөхсәт биргән Һади Максуди аның кыюлыгыннан куркып, кичен үзе типографиягә килә, бик ныгытып «төзәтә»-кыскарта, һәм ул мәкалә тешсез, рухы коелган, авторның фикере бозылган нәрсә булып кала.

Мин Һади әфәндедән мәкаләмне ничек язылган, шул көе, «редакцияләмичә» яңадан басуны сорадым, әгәр моңа риза

булмаса редакциядән китәчәгемне белдердем. Ул минем үтенечне кабул итмәде, мәкаләне яңадан бастырмады. Мин бу турыда яңадан сүз башласам да, уртак телгә килә алмадык. Мин киттем. Бергә эшләгән иптәшләремнең күңелләре кырылмасын дип, бернинди сәбәпләрен әйтмичә, «Йолдыз» газетасыннан китүем турында «Кояш» газетасында хәбәр бастырдым.

ОЧРАШУ

«Йолдыз»дан киттем. Революция дәвам итә, илдә төрле үзгәрешләр бара. Миннән соң газетаның күпме эшләвен белмим, миңа калса «Йолдыз» 1917 елның җәй башларында чыгудан туктады булса кирәк[1].

Моннан соң мин Һади Максуди белән очраштым әле. Бу дусларча очрашу булды. Бу елларда эчемлек табу мәсьәләсе авырайган иде. Каенагам Йосыфлар өенең чардагында берничә шешә «өч йолдызлы» бар икән. Хатыным Камилә, Газизә ханым белән киңәшеп, менә шушы «табыш» белән газетада эшләгән дусларыбызны сыйларга булдык. Кабан күле буендагы фатирыбызда кунак мәҗлесе җыйдык. Чакырылган журналистлар арасында иң өлкән һәм хөрмәтле, Казан журналистикасының «аксакалы» Һади әфәнде Максуди, аның антиподы, «Кояш» газетасының башъязар мөхәррире Фатыйх Әмирхан, Һади әфәндегә симпатиясе булмаган Фуад Туктаров та бар иде. Арабызда иң вәкарле язучы, соңыннан «Корылтай» газетасы эшендә катнашкан Җамалетдин Вәлиди дә бар иде. Мәҗлескә төрле юнәлештә эшләүче, төрле караштa торучы журналист, матбуга зыялылары чакырылган иде. Очрашу бик матур үтте, хатыным белән бу мәҗлестән бик мәмнүн булып калдык.

Бераз күңел ачып алганнан соң, Фуад Туктаров белән Һади Максуди бәхәсләшеп алдылар, шулай булса да бәхәс югары интонацияләргә күчмәде, очрашу дустанә узды.

Бу вакыттагы хәлләр төрле юнәлештә сәяси эш алып баручы прогрессив карашлы кешеләрне дә якынайта, бер-берсен аңларга файдалы иде. Бу эшлекләләрнең бары икесе генә (Фуад Туктар һәм мин) Русиядән киттек. Минем дустым, мөхәррир Җамалетдин Вәлиди, үзенең «Татар теленең тулы сүзлеге»н тәмамлап бетерү өчен Казанда калды, аны башка-

[1] Газета 1918 елның җәендә чыга башлаудан туктый.—*Ә. К.*

рып чыгып җиткерә алмады, ЧК зинданында авырып, төрмә больницасында үлде.

Аягы авыру, кул арбасы ярдәмендә генә йөри алучы драматург һәм язучы Фатыйх Әмирхан 1924, әллә 1925 елда Казанда вафат булды.[1]

Казанда адвокат булып эшләгән Фуад Туктар Анкарада үзенең профессиясе һәм белеме буенча эш таба алмады, кече бер мәэмүр (чиновник) булып эшләде, тормышы авыр булды, 1938 елның 19 декабрендә дөньядан китте[2]. Вакытында Казанда өйләнгән иде. Анкарада да ике тапкыр тормыш корып карады, берсеннән дә балалары булмады.

СОҢГЫ СҮЗ

Һади Максудиның вафаты турындагы хәбәр Анкарага 1941 елның кышында килеп җитә. Шул уңай белән мин «Яни сабах» газетасының 1941 ел, 17 ноябрь санында халкыбызның мәшһүр бу зыялысының тормышы һәм эшчәнлеге турында зур мәкалә белән чыктым. «Рус ихтилалыннан хатирәләр» исемле 1947 елда Истанбулда басылган китабымда да аның турында мәгълүматлар урнаштырдым. Минем «Яни сабах»та басылган мәкаләм Анкара университеты Хокук факультеты профессоры Садри Максудиның абыйсы турында иде. Садри Максудиның зур мөхтәрәм кеше, зур галим булып җитешүендә абыйсының йогынтысы да зур була.

---

[1] 1926 елның 9 мартында—*Ә. К.*

[2] Казанда чыккан «Корылтай» газетасында миндә эшләгән, минем белән бергәләп Себер юлларын таптаган Ф. Туктар 1938 елның 12 ноябрендә (үләргә бер ай һәм бер атна кала) Гаяз Исхакыйга язган хатында үзенең «Милли яшәешебезне торгызу өчен кырык еллык көрәш» исеме хатирәләр язарга уйлавын һәм аны Берлинда Гаяз Исхакый чыгара торган матбугат битләрендә басып чыгару мөмкинлеген белешә. Бәлки ул бу мемуарларын яза да башлагандыр, ләкин гомере аз калган булып чыкты. Тәңре ярлыкасын!

Мәрхүмнең бу хаты «Мәрхүм Фуад Туктарның мәктүбе» исеме астында 1939 елны «Яңа милли юл» газетасының февраль аендагы 130 санында басылып чыкты. Шул ук санда Гаяз Исхакыйның Фуад Туктар турында зур гына мәкаләсе дә урнаштырылган иде. *Г. Б.*

БУ ӘСӘРНЕҢ «А» БҮЛЕГЕНӘ КУШЫМТА[1]

ЕРАК КӨНЧЫГЫШТАН ХАТ

1934 елның августында, мин Истанбулда ялда вакытта, Тышкы эшләр министрлыгына, минем Анкарадагы адреска язылган бер пакет килеп төшә. Конверт Япониянең Кобэ шәһәреннән. Анда бер үк эчтәлекле өч хат, берсе Йосыф Акчура, икенчесе Садри Максудига тапшыру өчен дип күрсәтелсәләр дә, барысы да бергә минем адреска җибәрелгән конвертка салынган иде. Хат гарәп хәрефләре, нечкә каләм, гарәп язуының төрле стильләре кулланып язылган иде.

Миңа адресланган хат «Фәнни хезмәткәр, милләт хадиме...» дип башлана һәм «Милли җәмгыятьнең рәисе, имам вә мөгаллим хаҗи Мидияр Имаметдин оглы Шәмуни» дип тәмамлана иде. Бу хатның фотокүчермәсен китерү яхшы булыр иде, тик моңа мөмкинлегебез булмады. Хәрефләрен үзгәртеп яңа төрек графикасында язсаң аның мәгънәсе тоныкланачак, шуңа күрә без аның эчтәлеген генә күрсәтеп үтәргә булдык. Минем җаваплардан имам куйган мәсьәләләрнең нәрсә турында баруын аңларсыз.

Бу вакытта С. Максуди Анкарада яши иде. Аңа адресланган хатны мин Анкарага җибәрдем. (Йосыф Акчурага ничек һәм кайда тапшыруымны хәтерләмим).

С. Максуди миңа яңа төрек-латин графикасында, шактый уйгур сүзләре кыстырып җавап язды.

---

[1] Г. Батталның бу хезмәтенең ксерокопиясен миңа 1991 елның декабрендә Анкарада вафат булган, дөньяга таралган татарларның рухи мирасын барлау, саклауга гомерен багышлаган Мәхмүт әфәнде Таһир җибәргән иде. Ул җибәргән ксерокопияләр арасында бу «Кушымта» юк иде. Без аны икенче чыганаклар буенча эзләп таптык.—*Ә. К.*

«7.VII.34 (Дөресе 7.VIII.34.—*Г. Б.*)

Мөхтәрәм Габдулла әфәнде!

Хатыгызны алдым. Ерак Шәрыктән килгән әйберне укыдым. Барыбыз бергәләп уртак җавап язсак кулай булыр иде. Аерым-аерым җавап биргәндә фикерләребез арасында төрлелек булуы бар. Тиз арада мин Истанбулга, бер съездга барачакмын. Очрашырбыз һәм бу мәсьәлә буенча да килешербез дип саныйм. Бу хатка алдан җавап проектын әзерләп куйсагыз, бу безнең эшне җиңеләйтер иде...

Хөрмәт белән Садри Максуди».

(Хатның калган өлеше сәлам һәм рәхмәтләрдән тора).

Шушы елның җәендә Истанбулда төрек теле белгечләренең съезды булды. Аның утырышларының берсендә без өчебез дә очраштык һәм якындагы бакчага чыгып Шәмунигә җавап язу турында киңәшләшә башладык. Йосыф Акчура «Мин ул вакыйгаларга катнашмаган кеше, шуңа күрә берни әйтә алмыйм», дип җиңел генә котылды. Шунда мин Акчураның Казан һәм Урал төрекләренең киләчәге, азатлыгы өчен янып-көеп эшләүче Гаяз Исхакый алып барган эшкә артык игътибар итмәвен аңладым. Аның бу сүзләре «Бу мәсьәләләрне сез башлаган икән, менә хәзер шул турыда сез үзегез җавап языгыз», дип яңгырады.

С. Максуди, мин сиңа бу хатка проект әзерләп куйсаң иде дип язган идем, әйдә шуны карыйк, диде. Минем бу проектны язмаганымны белгәч, «Ул вакытта мин аңа үз исемемнән җавап язармын», диде. Бу хәл Эчке Русия һәм Себер төрекләренең Идарәсе рәисе Япониядән килгән бу мөһим хатка тиешле әһәмият бирмәве булып чыга. Шәмуни хатына аның җавабы булдымы, җавап яздымы—моны мин ишетмәдем.

Шулай итеп җавап язу минем өскә төште. Тиз генә Анкарага кайттым һәм 1934 елның сентябрендә имам Мидияр Шәмунига түбәндәге хатны җибәрдем:

«Милли җәмгыять рәисе, имам вә мөгаллим, хаҗи Мидияр Имаметдин оглы Шәмуңига.

Сезнең 9.VII.1934 тарихлы хаттагы сорауларыгызга җавап.

Әфәндем, Сез күтәргән сорауларга җавап бирергә тырышып карыйм.

СОРАУ. Эмигрант милләттәшләребез арасында, шулай ук туган җиребездә, автономия, милли бәйсезлек өчен көрәшүче нинди дә булса хәрәкәт бармы?

ҖАВАП. Минемчә, сез Эчке Русия, икенче төрле әйткәндә, Идел-Урал мөселманнарының язмышы һәм киләчәген кайгырту буенча эш алып баручы хәрәкәт бармы дип сорыйсыз. Җавабым шулдыр: руслар арасында азчылыкны тәшкил иткән төрек-татарларның автономиясен яклаучылар эмигрантлар арасында да бар. Бәлки бу эш белән җитәкчелек итүче җәмгыять тә бардыр. Ләкин бу өлкәдәниндидер оешкан хәрәкәт күренми. Эмигрантлар арасында аерым, мөстәкыйль дәүләт төзү идеясен яклаучылар да бар. Бу сезнең хатыгыз логикасыннан да күренә.

СОРАУ. Сез эмиграциядәге ике төрле карашның кайсы ягының тарафдарлары булырга тәкъдим итәр идегез? Милли-мәдәни мөхтәрият яисә мөстәкыйль, аерым дәүләт төзүне, кайсысына кушылырга, яисә берсенә дә кушылмаскамы?

ҖАВАП. Сезнең кебек тәрбия һәм мәгърифәт өлкәсендә эшләүче кешеләргә, бигрәк тә чит илләрдә яшәүчеләргә сәяси оешмалар эшенә катнашу кирәк түгел дип саныйм. Чит, ят илләрдә яшәүче милләттәшләребез арасында милли-мәдәни эшләр алып бару, милли аңнарын саклау, милли хисләрен үстерү эше үзе зур бер фидакарьлектер.

СОРАУ. Туган илебездә Милли мәҗлеснең күпчелеге кайсы яклы? Милли-мәдәни мөхтәрият яки мөстәкыйль аерым дәүләт төзү яклымы?

ҖАВАП. Уфадагы Милли мәҗлес Эчке Русия мөселманнары өчен милли-мәдәни мөхтәрият принципларын кабул итеп, аны тормышка ашыру өчен Милли Идарә дә сайлады. Бу идарә 1918 елның җәенә хәтле генә эшли алды, аны совет хөкүмәте куып таратты. Соңыннан Милли мәҗлес Русия федерациясе эчендә Идел-Урал штаты, туфраклы дәүләт төзү буенча яңа карар кабул итте. Бу мәсьәләне өйрәнү өчен Казанда махсус комиссия төзелде. Милли мәҗлеснең күпчелеге менә шушы карар ягында. Хәзерге көнгә чаклы милләтебезнең интересларын хокукый нигездә яклый ала торган, Милли мәҗлеснең карарын үзгәртергә яки кире кагардай хокукый орган юк.

СОРАУ. Төркиядә яисә Аурупада Идел-Урал төрек-татар мөстәкыйль дәүләт төзү юлында эшләүче берәр мәркәз бармы?

ҖАВАП. Төркиядә мондый оешма юк. Аурупада шундый мөстәкыйль аерым дәүләт торгызу, төзү буенча эш алып баручы бер группа бар. Бу группаның эшчәнлеге бөтен

милләтнең, аның барлык кешеләренең теләкләрен тулысынча чагылдыра алмый.

СОРАУ. Сезнең шәхси карашыгыз: Сез мөхтәрият яки тулысынча аерылу яклымы?

ҖАВАП. Милли мәҗлес кабул иткән карарны безнең әлегә хәтле гамәлдән чыгарганыбыз юк.

Эчке Русия төрекләрнең Милли мәҗлесенең элекке депутаты, Казанда басылган «Корылтай» газетасының баш мөхәррире: Г. Баттал.
Анкара, 1934, сентябрь.

Г. Г. БАТТАЛ-ТАЙМАС

ДВА БРАТА МАКСУДИ

АХМЕТХАДИ
(1867—1941)

САДРИ АРСАЛ
(1879—1957)

ОТКЛИКИ И ОТЗЫВЫ

(В ОТНОШЕНИИ ТРЕХ ПЕРВЫХ КНИГ)[1]

Хасан Али Южель, деятель просвещения.
25 сентября 1958 г.

Получил Ваши книги. Обратил внимание на книгу «Муса Ярулла». Упомянутых Вами книг в моей библиотеке нет. В библиотеке «Заман» бывают старые книги, там поискал—нет. Причиной моих поисков является желание написать статью о покойном, которого я очень ценю, и о Вашей книге. По приезде в Анкару займусь этим делом. Ценю Вашу энергию. Нужно вспомнить деятельность этого человека и использовать с благодарностью его работы. Прошу простить за опоздание с ответом.

---

[1] В целях просвещения турецкого читателя о казанских, волжско-уральских татарах, да и для восстановления исторической памяти оказавшихся в Турции своих земляков, Г. Баттал приступил к созданию серии книг «Выдающиеся деятели из казанских тюрков». Все книги этой серии увидели свет на турецком языке в Стамбуле и были встречены с большой признательностью со стороны читателей как в Турции, так и среди востоковедов Европы. Первые три книги этой серии представляют описание жизни, творчества Ризаэтдина Фахретдина, Мусы Яруллы Биги, Галимджана Баруди, оставивших глубокий след в научной, общественной, просветительской жизни татарского народа. Четвертая книга серии, которую Вы держите в руках, посвящена братьям Максуди (Стамбул, 1959). Она начинается отрывками из откликов и отзывов о первых трех книгах этой серии, полученных автором от ученых, писателей, общественных деятелей. Все эти работы написаны Г. Батталом и изданы за свой счет. (Примечание А. Г. Каримуллина. В дальнейшем его примечания будут обозначаться—*А. К.*).

Мирза Бала-Кутлук, азербайджанский ученый.
Мюнхен, 17 декабря 1958 г.

Серия «Выдающиеся деятели из казанских тюрок» превосходна. Это начинание заслуживает серьезного одобрения. По этому поводу я хочу написать похвальный отзыв в журнал «Dergi». Не знаю, скоро ли сумею закончить. (Этот научный и политический деятель скончался 8 марта 1959 г.).

Тахир Шакир-Чагатай, доцент социологических наук.
Анкара, 27 декабря 1958 г.

Прочитал внимательно все три брошюры. Считаю, что все три произведения заслуживают одобрения и являются поучительными. Я понял, что о них разные люди говорят по-разному. Думаю, что это происходит оттого, что каждый мерит на свой аршин. Неправильно такие серьезные вопросы оценивать простым эмоциональным восприятием. Считаю, что все три произведения («Ризаэтдин Фахретдин», «Муса Ярулла Биги», «Галимджан Баруди») с точки зрения содержания являются хорошими, продуманными. Усилия Ваши достойны, заслуживают признания. Надо Вас благодарить за то, что Вы вспоминаете людей, живущих в условиях государства в бедственном положении. Надеюсь, что Вы еще больше развернете свою деятельность и будете образцом в выполнении своих обязанностей перед нашими земляками, учеными.

Профессор фон Габайн.
Гамбург.
(Написано доктором Хамит Кошай).

Большое спасибо за книгу Баттал-Таймаса «Выдающиеся деятели из казанских тюрок». Меня это очень интересует, так как мне было неизвестно, как среди многих казанских деятелей пробуждается стремление к реформам. Сейчас у меня имеется представление об этом.

И. Мюхендис Кемаль Лукман.
Анкара, 28 сентября 1958 г.

Эти две книги («Разаэтдин Фахретдин» и «Муса Ярулла Биги») являются для нас, людей, расставшихся с детства со

своей родиной, очень ценными. Мы получаем хотя бы краткие сведения о своих великих ученых. Хотя мы имеем кое-какие сведения об этих ученых по литературе и печатным изданиям, все же у нас не было таких подробных (основательных) произведений. Ваши книги достойны признания. Объяснять отсутствие материалов пребыванием в эмиграции и уповать на лучшие времена—неправильно.

Имам Ахмед Хаким.
Хельсинки, 10 августа 1958 г.

Дорогой Таймас, я прочитал Вашу прекрасную книгу о покойном Мусе Ярулле. Я чрезвычайно доволен тем, что Вы надлежащим образом оценили общественно полезную деятельность покойного учителя и в своей брошюре привели его прекрасные высказывания и разумные мысли. Статьи, написанные в газетах, сборниках, исчезают, они не сохраняются, а работы в виде монографий никогда не теряются, живут вместе с человечеством. Написав своим искусным, умелым пером эту брошюру, Вы возродили покойного учителя. Эта великая честь принадлежит Вам. Нельзя и говорить о том, чтобы написать его биографию на его собственной родине, даже неизвестно и местонахождение его семьи.

Прочитал Вашу брошюру и о Ризаэтдине хазрате. Да будет довольна душа покойного Вашим трудом. Мне лично и эта Ваша книга очень понравилась, была полезна.

Ценную книгу об учителе Галимджане Баруди также прочитал и высоко ценю. Хотя он более 35 лет жизни посвятил трудам и заботам по воспитанию многих и многих учеников, ни одному из его учеников не удалось подробно описать историю его жизни, его нравственные устои и научную деятельность. Эта честь также выпала на Вашу долю. Описать жизнь и общественно полезную деятельность великого ученого—задача не из легких. За это мы Вам очень благодарны, дорогой учитель.

Имам Хабибрахман Шакир.
Тампере (Финляндия), 20 сентября 1958.

Ваши две книги о Мусе Ярулле и Ризаэтдине Фахретдине я получил в подарок от Халиды Вафа (туташ). По прочтении этих книг я решил написать Вам письмо с выражением

своей признательности и своего почтения. Желаю Вам доброго здоровья, чтобы Вы могли еще написать подобные книги. Ваша книга о Мусе Ярулле меня полностью удовлетворила. Я являюсь учеником и последователем Мусы хазрата. Период жизни покойного в Индии проходил также при мне. В этом отношении у меня много сведений.

Профессор Б. Шпулер.
Гамбург, 24 ноября 1958 г.

Шлю Вам большую благодарность за присылку мне двух ценных книг. Ввиду того, что я написал книгу о жизни татар и башкир в Русском государстве, эти вопросы меня чрезвычайно интересуют. Ваши книги я прочитаю с большим интересом.

Профессор Матти Ресенен.
Хельсинки, 9 февраля 1959 г.

Многоуважаемый коллега Габдулла Б-Т.
Весьма благодарен за посланные мне книги о знаменитых людях Казани. Желаю Вам продолжать Ваши труды в этой области.

Зухур Тахир, Председатель общества тюрко-ислам.
Хельсинки, 1 августа 1958 г.

Получив Вашу книгу о Мусе Ярулле, выражаю большую благодарность. Биографию Мусы Яруллы Вы написали подробно. Я постараюсь ознакомить здешнее общество с Вашими книгами.

Доктор Хамит Кошай.
Анкара, 5 декабря 1958 г.

Внимательно прочитал Вашу книгу о Галимджане Баруди. Да будут признаны Ваши усилия. Я уверен, что Вы оказали большую услугу этому ученому.

Сами Н. Озердим, директор национальной библиотеки Турции.
Анкара, 15 января 1959 г.

В предыдущем номере журнала «Турк дили» во главе краткого списка печатных изданий я привел Ваши три биографии. Вы должны признать, что я в этой области не компетентен. По этой причине я просто выполнил свой долг в отношении Ваших книг. Прошу прощения.

А. Беннигсен.
Париж, 3 октября 1958 г.

Я получил из Стамбула Ваши ценные монографии о Ризаэтдине Фахретдине и Мусе Ярулле Биги. К сожалению, в книжных магазинах я не смог найти монографии о Галимджане Баруди, «Два Максуди», а также Ваши более ранние работы: «Казанские тюрки» («Казан төрекләре», Стамбул, 1925), «Воспоминания о русской революции» («Урыс ихтилалыннан хатирәләр», Стамбул, 1947), «Народы, отделившиеся от России» («Русиядән аерылган милләтләр», Анкара, 1927) и «Историю тюрко-татар» («Төрек-татар тарихы», Мукден, 1938). Я об этом очень сожалею, так как они были бы чрезвычайно нужны для моих исследований.

Халида Вафа.
Тампере (Финляндия), 12 сентября 1958 г.

Как только я прочитала эти Ваши две книги, я обратила на них внимание нашей молодежи. Они встретили с вниманием и радостью труды, посвященные национально-культурному развитию. В настоящее время они их изучают, но в дальнейшем они еще больше оценят их. Я решила на собраниях тюрков в Тампере по возможности рекламировать Ваши книги.

Халит Рашит.
Нью-Йорк, 27 декабря 1958 г.

Опубликованные книги о жизнедеятельности великих людей, имеющих большие заслуги перед нашим народом, явля-

ются Вашей большой заслугой. Желаю Вам здоровья, счастья, долгих лет жизни.

Учитель Абдерахим Уйгур Озентюрк.
Кула, 15 марта 1959 г.

Дорогой учитель, поздравляю Вас с изданными Вашими произведениями. С глубоким удовольствием читаю Ваши книги. Желаю Вам долгих лет жизни. Очень хочется, чтобы Вы продолжали и далее плодотворно трудиться в этой области.

Асим Зихниоглу (Текеллерден).
Стамбул, 3 апреля 1959 г.

Три Ваших книги получил с удовольствием. Поздравляю от души с успешными результатами Ваших трудов.

Рефик Оздек, юрист.
Стамбул, 16 октября 1958 г.

С радостью получил Ваши ценные книги. Они очень полезны для ознакомления с жизнедеятельностью великих людей, имевших большие заслуги в деле нашего национального развития. Надеюсь читать в дальнейшем Ваши новые труды в области культуры и искусства наших северных родичей. Меня весьма радует Ваша плодотворная работа, желаю Вам от всего сердца дальнейшего успеха в работе.

Лютфи Икиз, библиотекарь.
Невшехир, 8 июня 1959 г.

Читал Ваши опубликованные ценные произведения. Поздравляю Вас и желаю Вам написать еще много произведений. Публикации Ваши будут бессмертны...

Абдулкадыр Инан, тюрколог.
Анкара, 31 июля 1959 г.

Дорогой господин Г. Баттал. Получил любезно Вами присланные две Ваши книги. Премного Вам благодарен. Поздравляю Вас с успешными трудами на пользу нации, желаю дальнейшей плодотворной работы. Эти великие служители за

национальную культуру заслуживают памяти. В течение сорока лет мы только и изнываем, говоря, что столько несправедливости терпит наша нация на севере от власть имущих. Ваши начинания весьма полезны, Вы несете при этом и материальные затраты. Повторно выражаю Вам свою большую благодарность.

ВСТУПЛЕНИЕ

В Казанской области в Заказанском районе[1], деревне Ташсу был мулла Низамеддин Максуди, у которого было три сына: Ахмедхади, Салахутдин и Садреддин (Садри) Максуди. В духовной и культурной жизни казанских татар старший и младший братья сыграли значительную роль. Средний брат Салахутдин не получил большого образования, но был человеком деятельным и принял участие в торговой жизни казанских тюрок, он открыл на Сенном базаре магазин кожевенных товаров.

Нас интересуют старший и младший братья—это два Максуди.

Ввиду того, что известность младшего брата является значительно более широкой, мы свое изложение начинаем с описания жизни и деятельности младшего брата. Естественно, что дело не в возрасте, а в полезной деятельности и знаниях. Старший брат был педагогом и газетным работником. Он прославился как автор учебников.

Младший брат являлся политическим деятелем. Научной деятельностью начал заниматься после выезда из России в возрасте 40 лет. Как в политической деятельности, так и в научной работе у него были большие заслуги, и он в этом отношении опередил старшего брата. По развитию, по подготовке, по образованию он был выше, кроме того, его приезд

---

[1] Села, расположенные севернее Казани, у населения именуются как «Заказанье»—«Казан арты». Это нашло отражение и в одном из стихотворений казанского поэта Г. Тукая:

«Аерылып китсәм дә синнән гомеремнең таңында мин,
И, Казан арты! Сиңа кайттым сөенеп тагын да мин».

И родная деревня поэта Кушлавыч находится в Заказанье. (Примечание Г. Г. Баттал-Таймаса. В дальнейшем его примечания будут обозначаться—*Г. Б.*).

в Турцию открыл ему широкие возможности для научных исследований, где он добился больших успехов и признания.

Садри Максуди в Турции являлся не столько политическим деятелем, сколько просветителем, который вел весьма полезную работу в качестве человека с большой эрудицией и своей творческой научной деятельностью служил турецкому народу.

Политической деятельностью в Турции он не занимался. Здесь он предал забвению и тему, над которой начал работать в Европе,—«Политические чаяния тюркских народов России и Сибири». Возможно, у него не было на это и времени.

Его приезд из Франции в Турцию был большим событием. Никогда не будут забыты и те, кто пригласил его в дорогую нам страну и дал ему возможность благотворно заниматься творческой, научной деятельностью.

У старшего брата А.-Х. Максуди, оставшегося в Казани после революции, условия жизни были нелегкие. В этот период он не мог заниматься ни в области педагогики, ни в газете. Он оставил публицистическую деятельность, его учебники пережили свое время. Младший же брат продолжал развиваться и прогрессировать в области науки, в материальном же положении не испытывал трудностей и стеснений.

У старшего брата творческая деятельность прекратилась, в материальном положении он испытывал исключительные затруднения. Словом, свои последние 23—24 года он провел в постоянном страхе и огорчениях. Этот человек умственного труда не смог уже ничего дать людям и в несчастии закрыл свои глаза. А.-Хади эфенди, будучи чрезвычайно осторожным человеком, сумел выжить и при Советах, но ему не удалось служить светлому делу нации, так он ушел из общественной жизни (см. раздел В).

Садри Максуди был умеренным националистом-туркистом. На своих лекциях, конференциях и в трудах очень любил развивать дискуссии о путях национального развития. В области политико-экономической жизни он был сторонником либерализма. Он не принял социализма. Карла Маркса признавал в качестве философа-социолога, но как строитель бесклассового общества, как идеолог классовой борьбы Маркс его не очень интересовал. В противоположность великому земляку Юсифу Акчуре С. Максуди не признавал ведущей роли социально-общественных факторов в жизни человечества,

он придавал большее значение силе мысли, идеям и великим личностям. К этому заключению можно прийти из его выступления на конференции первого турецкого исторического конгресса «Факторы, движущие историю».

В области государственного управления С. Максуди не был сторонником революции. Он принадлежал к политической партии кадетов. Но затем пересмотрел свои взгляды и стал сторонником республиканского строя, был, без сомнения, также приверженцем демократии. Однако в силу того, что он по духу и чувствам был аристократом, его демократичность была скорее теоретически-научной. Он не мог влиться в demos и жить его чаяниями и надеждами и если нужно быть жертвой на этом пути, следуя философии Хекима Саади из Шираза. Он был демократом, который предпочитал не оставаться в тени. Мне вспоминается по этому поводу высказывание одного философа в одной повести: «В сущности я сторонник социализма, но предпочел бы, чтобы этот строй воплотился в жизнь после моей смерти». (Это по существу изречение французского короля: «Apres moi le delenge»).

Характер у покойного не был привлекательным, но был достойным. По натуре он походил на старшего брата, в нем тоже иногда чувствовались странные помыслы и действия. Один наш остроумный земляк заметил: «Хади эфенди—это небритый Садри, а Садри—это бритый Хади эфенди».

Садри Максуди высоко ценил себя, был высокомерным и раздражительным. Он не терпел юмора и шуток, но не был и злопамятным, не таил в себе ненависти. Доказательством тому можно привести следующее. Его коллега юношеских лет писатель Гаяз Исхаки и сотрудник газеты Фуад Туктаров в дни революции 1905 года и в период между двумя революциями (1905—1917) в печати выступали о нем с нелестными высказываниями. Садри бей с первым из них в период последней революции пришел к взаимопониманию, а с другим в Париже работали вместе в Комиссии по защите прав тюрко-татарских народов. Одним словом, покойный умел отличать личное от общественного.

В одном из писем мне из Стамбула (18 февраля 1946 года) о своей выдержке и доброжелательности он пишет следующим образом: «Этому имеются две причины: первое—это нравственное убеждение в том, что на небольшие недостатки и слабости людей надо закрывать глаза, не замечать и стараться их забыть—это является нравственной обязанностью

человека. Вторая причина психологическая...» (Эти слова были написаны мне для выяснения наших взаимоотношений, затем в письме приводятся психологические причины, которые я здесь не буду приводить.—Г. Б.). По-видимому, вследствие этих свойств характера он говорил, что ни к кому не питает враждебных чувств. Спрашивается, в течение всей его жизни был ли у него искренний задушевный друг или нет? Собеседования с ним, с одной стороны, были очень приятны, так как он был человеком весьма эрудированным, с большим пониманием жизни, видным ученым; с другой стороны—были тяжелы, т. к. разговор он любил вести в нужном ему направлении, если разговор был не по его вкусу, он начинал нервничать. Я тоже был свидетелем такого рода нервничания. Однажды в Анкаре, в районе Нового города, мы с ним встретились в кондитерской и начали беседовать. Видимо, что-то его задело, он сразу обиделся и сказал: «Вы всегда были настроены против меня», встал и ушел. Между тем он не был прав. Я никогда не был настроен против него, но я избегал чрезмерно его восхвалять и только. Очевидно, он сам потом понял, что был неправ по отношению ко мне, т. к. после этого случая мы с ним много раз беседовали. Это тоже доказывает, что он хотя и был обидчивым, но не был злопамятным.

Хотя Садри Максуди был крепкого телосложения и в основном здоровым человеком, с годами во внутренних органах и в нервной системе начали проявляться некоторые осложнения. В бытность в Анкаре время от времени переносил приступы болезни. Об этом говорили лечащие его врачи, сам же он об этом не говорил и старался держаться как будто ничего не случилось. За 3—5 лет до смерти в Стамбуле он перенес тяжелую болезнь (видимо, в области поджелудочной железы) и находился на излечении в больнице. Но, несмотря на болезни, даже после ухода с государственной службы он продолжал свою творческую деятельность, много читал и много писал. Он говорил, что не является журналистом, но, живя в Стамбуле, в районе Османбей на улице поэта Нигар, в газету «Тасвир» он писал статьи. Он не желал быть забытым, и в пожилом возрасте продолжал трудиться. После ухода на пенсию и пятилетнего отдыха в 1950 году выдвинул свою кандидатуру на выборах в Анкаре. В том же году он ездил в районы для выступлений в предвыборных кампаниях. Я помню, как он усталый вернулся из этой поездки. В то вре-

мя ему было около 72 лет. В 1954 году он кандидатуру свою не выдвинул и не был выдвинут. Последние 6—7 лет жизни он занимался изданием своих трудов, а также продолжал творческую работу.

